БЕЗДӘ – ЯҢА ПРОЕКТ

Редакциядә җыелып, милли тормыш турында фикер алыштык

> 6–7

ГАИЛӘ БАШЛЫГЫ

Бу якшәмбедә Әтиләр көне билгеләп үтелә. Әйткәннәрен тыңлыйлармы, үрнәк була беләләрме?

> 16

КАРТАЙМАСЫН НАЛАСА

Бу авылда ике катлы йортлар бер катлыларына караганда күбрәк

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 150 (29117) | Җомга | 13 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илүзә Шәрәфиеваның шәхси архивыннан

ҖИР КЕШЕСЕ

КАЗАНДА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ХЕЗМӘТЧӘННӘРЕН ХӨРМӘТЛӘДЕЛӘР

Бүген тамагыбыз тук, табыныбыз мул икән, иң элек без әнә шул кешеләргә рәхмәтле. Иртә таңнан уянып, кичкә кадәр үзен генә түгел, шәһәр халкын да кайгыртып яши җир кешесе. Игенен игә, терлеген үстерә, әле авылның рухын сакларга да тырыша ул. Маңгай тирен түккәндә, көчне каян ала? Күңелендә нинди борчу бар? Иртәгәдән ни көтә? Бу хакта аларның үзләреннән сорадык.

> 5

Ишетми калмагыз

Ана капиталы күләме арта. Киләсе елда аның суммасы беренче балага – 631 мең сум, икенче һәм аннан соңгы балага 834 мең сум тәшкил итәчәк. Россия хезмәт һәм социаль яклау министры Антон Котяков әйтүенчә, бала акчасы инфляция күрсәткече күләмендә – 7,5 процентка үсә.

Киләсе елда 1 миллионнан артыграк гаиләнең сертификат алуы көтелә. Министр сүзләренә караганда, хәзерге вакытта ана капиталы күбрәк торак сатып алуга тотыла. Ел башыннан бирле шул акча бәрабәренә 470 меңгә якын гаилә торак шартларын яхшырткан. Акчаны 3 яшькә кадәрге балага айлык түләү рәвешендә рәсмиләштерүчеләр дә байтак. 318 меңнән артыграк гаилә шуны сайлаган. Тагын 205 мең ата-ана капиталны балаларын укытуга тоткан.

Быел тугыз айда Татарстанда барлыгы 1,6 миллион квадрат метр шәхси торак мәйданы файдаланугa тапшырылган. Еллык план арттырып үтәлгән дә инде, дигән сүз бу. Агымдагы елда барлыгы 10,4 мең шәхси йорт (гомуми мәйданы – 1,5 миллион кв. метр) төзергә тиеш булганнар.

Республикада тугыз айда җәмгысы 2,8 миллион кв. метр мәйданда торак төзеп тапшырылган. Бу – еллык планның 93 проценты.

Сентябрьдә Татарстан такси бәясе буенча Идел буе федераль округы төбәкләре арасында җиденче урынга чыккан. Бездә 1 чакрым юл узу уртача 30,56 сумга төшкән. Такси бәясе хакы бер айда уртача 3 процентка күтәрелгән.

Федераль округта иң югары бәя – Пермь краенда. Бу төбәктә таксида 1 чакрым юл узган өчен уртача 36,65 сум түләргә кирәк булган. Икенче урында – Киров өлкәсе (35,48 сум), Мари Эл – өченче (34,76 сум). Округта таксида 1 чакрым юл узу өчен 30,87 сум түлисе.

Атна ахырында Татарстанда берникадәр җылыта: көндез һава температурасы +17 градуска җитәчәк. Киләсе атна башында тагын суытачак. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә – 14 октябрьдә көндез һава температурасы +7...+12 градус булыр дип көтелә. Явым-төшем ихтималы аз. Төнге сәгатьләрдә +1...+6 градус. Якшәмбе – 15 октябрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +12...+17 градуска кадәр күтәреләчәк. Аз гына яңгыр явып үтәргә мөмкин. Төнлә +2...+7 градус. Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, дүшәмбе – 16 октябрьдә явым-төшем ихтималы аз. Көндез һава температурасы +12...+17 градуска җитәчәк. Сишәмбе – 17 октябрьдә Татарстанга суык һава үтеп керәчәк. Көчле җил һәм яңгыр булуы фаразлана. Көндез +8...+13 градус.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Ел башыннан бирле районның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләре 34 баланы гаиләгә урнаштырган. «26 бала туганнары карамагына тапшырылган, 4 бала тәрбиягә алынган, 2 бала уллыкка алынган һәм 2 яшь түбәнкамалы үз гаиләсенә кайтарылган», – диде «эшлекле дүшәмбе» утырышында әлеге бүлек җитәкчесе Наталья Шибаева. Баланы тәрбиягә алырга теләгән кандидатлар исемлегендә 50 гаилә һәм ялгызы гына яшәүче 19 кеше бар. 1 октябрьгә булган мәгълүматларга караганда, районда ата-ана назыннан мәхрүм калган 39 бала ачыкланган һәм исәпкә куелган. Гомумән алганда, опека һәм попечительлек бүлегендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган 508 бала исәптә тора. Аларның 249ы уллыка алынган, 196сы – туганнарында, ә 63е тәрбиягә алган гаиләләрдә яши. Тагын 27 бала балалар йортында, 8 үсмер башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнә.
tat.e-nkama.ru

Әлмәт

Бу елның сентябрь аенда Әлмәт районында 146 сабый дөньяга аваз салган. Аларның 75е – малай, 71е – кыз. Иң кечкенә баланың авырлыгы – 1460, иң зурыныкы – 4560 грамм. Иң яшь әнигә – 17 булса, иң өлкән әнигә – 42 яшь. Иң яшь әтигә – 21, ә иң өлкәненә – 55 яшь. Әлмәтлеләр балаларына ешрак Злата, Лев, Мия, Мирон, Ясминә, Амелия, Усман, Матвей, Алина, Мәрьям, Марк исемнәрен куша. Иң сирәк кушыла торган исемнәр рәтендә Каролина, Василиса, Алия, Азиза һ.б. бар.
(«Әлмәт таңнары»)

Буа

Шәһәрнең татар зиратында мемориаль комплекс барлыкка киләчәк. Быел анда танылган дин эшлеклеләре, имамнар һәм меценатларның каберләрен тәртипкә китерәләр. Бу хакта Буа районы башлыгы Рәнис Камартдинов үзенең Telegram-каналында хәбәр итте. Татар зиратының 500 елдан артык тарихы бар. Анда Габделвахид бин Габдеррахман (1808–1852), Габденнасыйр Мөхәммәдәминов (1806–1886), Нургали Хәсәнов (1852–1919) кебек танылган галим, мәгърифәтче һәм дин эшлеклеләренең кабер ташлары урнашкан.
(«Татар-информ»)

Тукай

Илбухтино авылында яңа фельдшер-акушерлык пункты ачылды. Шул көннән авыл җирлегендә яшәүчеләр барлык кирәкле квалификацияле медицина ярдәме ала башлады, шулай ук уңайлы шартларда профилактик тикшерүләр узачак.
(Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте)

ДӘВАМЛЫ ЮЛ

tatarstan.ru

Казанда Вознесение тракты буенча салынучы юлның беренче өлешен ачтылар. Ул Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәр дәвам итә. Ачылыш тантанасы юл хуҗалыгы тармагы хезмәткәрләренең «Юл – 2023» илкүләм съезды кысасында узды.

Росавтодор башлыгы Роман Новиков видеоэлемтә аша республика юлчыларын һөнәри бәйрәмнәре – Юл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне белән котлады. Ул искәртеп үткәнчә, съезд кысасында ел саен илнең төрле төбәкләрендә яңа юллар, юл объектлары ачыла. Быел, мәсәлән, Татарстан белән бергә яңа юлдан Архангельск һәм Свердловск өлкәләрендә яшәүчеләр дә узды.

– Вознесение тракты – республикадагы мөһим объект, аның яхшы тарихы бар, – диде Роман Новиков. – Ул Татарстан җитәкчелегенең үз дигәнендә нык торуы нәтиҗәсендә генә тормышка ашты. Вознесение трактының бер өлеше булган Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәрге хәрәкәт Казанда яшәүчеләр өчен шәһәрдән чыгу юлын тагын да җиңеләйтәчәк, шулай ук транспорт уңайлылыгын тәэмин итәчәк.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, юл төзелеше дәвамлы булачак.

– Без Вознесение трактының иң катлаулы өлешендә хәрәкәт ачабыз. Ул федераль үзәкнең зур ярдәме белән төзелде. Проектны тормышка ашыруда теләктәшлек күрсәткәннәре өчен Россия Президенты Владимир Путинга, ил Хөкүмәтенә, Россия Транспорт министрлыгына һәм Росавтодорга зур рәхмәт. Әлеге катлаулы юл участогы 13,4 миллиард сум тора! Әлбәттә, аның дәвамы да булачак. Без алга таба да ярдәм сорап мөрәҗәгать итәчәкбез. Барыгызга да зур рәхмәт! – диде Рәис.

Билгеле булганча, Вознесение тракты проекты бөтен республика өчен әһәмиятле проект булып санала. Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәрге юл аның беренче этабын тәшкил итә. Яңа ачылган юлның озынлыгы – 4 чакрым. Алга таба әлеге юл транспорт хәрәкәтенә бәйле вазгыятьне генә җиңеләйтеп калмыйча, бу тирәдә торак төзелешен арттырырга мөмкинлек бирер дип көтелә.

АККАН СУГА КАРАП

2025 елда республикада елга маршрутында пассажир санын 500 меңгә кадәр җиткермәкчеләр. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә узган киңәшмәдә әйтте.

Россия Транспорт министрлыгында илнең эчке су юлларыннан пассажирлар йөртү һәм тармакның үсеше турында сөйләштеләр. Киңәшмәне министр Виталий Савельев үткәрде. Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, Татарстанның эчке су юлларының озынлыгы 1 мең чакрымнан артып китә. Республикада социаль әһәмияттәге елга пассажир маршрутлары сакланган. Рәис су буйлап йөк ташуга да аерым тукталды. Аның әйтүенчә, республика ярдәме белән йөк ташулар беркайчан да туктап тормады, моның өчен төбәк бюджетыннан акча да каралган.

– Хәзер без бу юнәлешне үстерәбез. Яңа причаллар төзелә, булганнары яңартыла. Флотка ремонт ясала. Быел Яшел Үзәндәге Горький исемендәге заводтан өч яңа судно сатып алдык, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Хәтерләсәгез, быелның маенда республикада «Татарстан флоты» компаниясе төзелү турында билгеле булды. Оешманың устав капиталы 2 миллиард сум күләмендә республика бюджеты инвестицияләреннән гыйбарәт. Барлык акцияләргә дә Татарстан үзе хуҗа булачак. Җәй көне яңа судноларны суга төшергәндә, Рөстәм Миңнеханов, «Метеор 2020»гә утырып, Казансу буйлап йөреп тә кайтты.

– Бүген илнең судноларны төзелеше тармагы үзебездә төпләнгән заманча проектларга кытлык кичерә. Бу җәһәттән, Татарстанда мондый тәҗрибә бар. Ил күләмендә сыекландырылган табигый газ ярдәмендә эшләүче тәүге пассажир судносын нәкъ менә бирегә төзеделәр. Лизинг компаниясе республика белән күптәннән хезмәт итә. Әлеге хезмәттәшлек Россия Хөкүмәте тарафыннан расланган ил судноларны төзелеше программасын тормышка ашырырга да ярдәм итәчәк дип ышанабыз. Аның кысасында төрле максатларда хезмәт итәчәк 250дән артык гражданнар судносы төзү каралган, – дип сөйләде «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» генераль директоры Евгений Дитрих, Казанга килгәч.

Әйткән сүз – аткан ук: республикада 2025 елда ук елга маршрутында пассажирлар санын 500 меңгә кадәр җиткермәкчеләр. Чагыштыру өчен: 2022 елгы навигация чорында республикада бу күрсәткеч 330 меңне тәшкил иткән.

Киңәшмәдә Петербург халыкара икътисадый форумында имзаланган «Бөек Идел юлы» проекты турында да искә алдылар. Ул ил төбәкләре арасында елга транспорты белән төбәкара пассажир ташуны үстерүне күздә тота. Әлегә бу эштә Татарстаннан тыш, Мари Эл, Чувашия республикалары, Самара, Ульян һәм Саратов өлкәләре катнаша. «Республика төбәкара хезмәттәшлеккә әзер», – диде Рәис.

Авырткан җир дә бар.

– Татарстанда Куйбышев сусаклагычының саегуы аркасында социаль киеренкелек саклана. Суның тирәнлек күрсәткече түбән булу сәбәпле, судноларны Идел һәм Чулман елгалары ярында урнашкан биш торак пунктка барып җитә алмый. Куйбышев сусаклагычының республика территориясендә аз сулы булуы «Бөек Идел юлы» төбәкара проектының төп бурычларын үтәүгә комачауларга мөмкин, – диде Рәис, җитәкчелекне дә, гади халыкны да борчуга салган мәсьәләгә тукталып.

ЯТЛАР ТҮГЕЛ

gossov.tatarstan.ru

Татарстан Дәүләт Советы делегациясе Алтай Республикасына сәфәр кылды. Ике республика парламентлары арасында яңа килешү имзаланды. Безнекеләр еракта яшәүче милләттәшләребезнең дә хәлен белеште.

Татарстан Дәүләт Советы һәм Алтай Республикасы Дәүләт Җыелышы – Эл Курултае арасында хезмәттәшлек турындагы килешүне парламент башлыклары Фәрит Мөхәммәтшин һәм Артур Кохоев имзалады. Бу – тәүге килешү түгел. Беренчесе 2004 елның июлендә төзелгән. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, депутатлар, җитәкчеләрнең аралашып торуы килешүне яңартуга сәбәп булды. «Алтай Республикасы белән агросәнәгать һәм туризм юнәлешләрендә хезмәттәшлекне үстерәсебез килә», – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин очрашуда парламент эшчәнлеге, республикадан сайланган Дәүләт Думасы депутатлары белән хезмәттәшлек, Татарстанда тынычлык һәм милләтара татулыкны саклау өчен башкарылган эш турында сөйләде. «Бу очрашу ике парламентның үзара хезмәттәшлеген ныгыту өчен яңа мөмкинлекләр ачар, ә безнең республикалар арасында дуслык ике республикага да файда китерер дип уйлыйм», – диде ул.

Алтай Республикасы Дәүләт Җыелышы – Эл Курултае рәисе Артур Кохоев фикеренчә, безнең халыклар тарихында һәм мәдәниятендә уртак яклар күп. «Яңартылган килешү безнең төбәкләр һәм парламентлар арасында дуслыкны, үзара файдалы хезмәттәшлекне ныгытуга яңа этәргеч бирер», – диде ул.

Тантана ахырында Артур Кохоев Фәрит Мөхәммәтшинга парламентара хезмәттәшлекне үстерүгә һәм ныгытуга зур шәхси өлеш керткәне өчен «Алтай Республикасы парламенты» истәлекле медален тапшырды.

Татарстан парламентарийларының сәфәре рәсми очрашулар белән генә чикләнмәде. Алар «Алтай – Евразия йөрәге» стеласы янында эрбет агачлары утырттылар. Сүз уңаеннан, әлеге стела Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән ясалган һәм Алтай халкының үз теләге белән Россия составына керүенә 250 ел тулу уңаеннан Алтай Республикасына бүләк итеп тапшырылган иде. Моннан тыш, Татарстан депутатлары Таулы Алтайның «Җиңү паркы» хәтер комплексында сугышчылар һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Танылган рәссам, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, Алтай дәүләтчелегенә нигез салучыларның берсе Григорий Чорос-Гуркинны искә алдылар.

Татарстан кунаклары Алтай Республикасында яшәүче милләттәшләребез белән дә очраштылар. Фәрит Мөхәммәтшин аларга Татарстан Рәисе, Дәүләт Советы һәм Хөкүмәтенең изге теләкләрен ирештерде.

– Бер очрашу – бер гомер, без бүген Алтай Республикасының уңышлы үсүенә бик шатбыз, – диде ул. – Үз традицияләрен, динен, телен саклап калучы кешеләрне чын күңелдән хөрмәт итәбез. Һәр халык үз телен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, милли киемнәрен һәм аш-суларын саклап калырга тели. Сез Алтай җирендә татар мәдәниятенең үзенчәлеген саклап яшисез. Россия Федерациясендәге күпмилләтле халыкның берләшүе әнә шул инде.

Дәүләт Советы Рәисе Алтай татарларына Татарстанда милләттәшләребез катнашында узучы зур чаралар, республикада белем һәм тәрбия бирү юнәлешендә башкарылган эшләр турында сөйләде. Аларга туган телне саклаган өчен рәхмәт белдерде. Хәзерге вакытта Алтай Республикасында татар милли-мәдәни үзәген булдыру турындагы документ әзерләнә.

БЕЛДЕРҮ

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын тикшерү буенча парламент тыңлаулары 19 октябрь көнне (14.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советының Кече залында үткәреләчәк.

Парламент тыңлаулары Татарстан Дәүләт Советының рәсми сайтында туры эфирда күрсәтеләчәк.

Закон проекты белән Дәүләт Советының рәсми сайтында танышырга мөмкин.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Шөкер итү

Бу сүзне мин беренче тапкыр әбидән ишеттем бугай. Еш әйтә иде. Бәрәңгене утыртып, яки алып бетерсәк тә, печән мәшәкатьләреннән котылсак та, утын-фәлән алып кайтсак та шуны кабатлый. Хәтта ниндидер ризык куеп, табынга утыртканда да теленнән төшерми: «Аллага шөкер!» – ди. Мондый вакытларда аның күзләрендә рәхмәт хисе, йөзендә балкыш хасил була, бар булмышын канәгатьлек били.

Асылын юньләп төшенеп җитмәгәч, миңа бу бераз сәер тоела. Олыларның шулай гел шөкер итеп, гел рәхмәт әйтеп торуы кызык бит инде бәләкәй кешегә. Ялагайлану сыман да тоела, гел шулай итеп Алла бабайның ачуын китерәдер дә кебек тоела. Бер карасаң, әйбәт тә шикелле. Әйбәттер инде ул, олы кеше белмичә эшләмидер… Шулай уйландырганы өчен хәтергә сеңеп калгандыр. Әбине искә төшергән саен аның Аллага шөкер иткәнен дә күз алдына китереп куям.

Хәзер үзебез дә олыгаябыз, шундыйрак булып барабыз инде. Нәрсә эшләсәк тә, шөкер итәбез. Нәрсәдер бирсәләр дә, шөкер итәбез. Бирмәсәләр, алмаганнары өчен шөкер итәбез. Алсалар, алып бетермәгәннәре, бераз калдырганнары өчен. Өлкән яшьтәге кешенең гомере шулай гел шөкер итүдән генә тора икән.

Яшь вакытта алай булмыйсың бит… Була да алмыйсың. Чөнки сау-сәламәт, матур, гайрәтең ташып тора, алдыңда – тулы бер гомер. Кемгә карасаң, шуны гашыйк итәсең. Нәрсәгә тотынсаң, шул кулыңнан килә. Алда әле тагын күпме мөмкинлекләр көтә. Яшәгән саен тәҗрибәң арта, остарасың, буең ныгытасың. Синең алда буйсынмас үрләр юк та, булмас та сыман тоела.

Ләкин син бернигә дә шөкер итмисең. Киресенчә, син барысына да канәгатьсезлек белдерәсең. Мең гүзәл куеныңа керергә атлыгып тора, ә мең дә беренчесе бик сер бирми. Һәм бу уңышсызлык фаҗига кебек тоела. Бер тәүлек эчендә йөз төрле эш башкарасың. Йөзе дә меңә дигән килеп чыга, тик йөз дә беренчесен эшләргә я вакытың, я көчең, я осталыгың җитми. Һәм син үзеңне булдыксыз итеп тоясың. Шундый вакытта рәхмәт әйтеп, шөкер итеп буламыни инде?! Алдыңда ниндидер мөһим вакыйгалар торганда кинәт авырып китәсең, я кайдадыр егылып төшәсең шунда, я кадакка басасың, я кулыңны сындырасың. Монысы да канәгатьләнергә ирек бирми торган бер начарлык, тормышның аяусызлыгы булып тоела. Чир ул әллә нигә бер генә, аз вакытка гына килсә дә, сагынып, колач җәеп каршылый торган нәрсә түгел бит инде. Үзен көчле, бар нәрсәгә сәләтле дип уйлаган вакытта кеше кечкенә уңышсызлыкларны да авыр кичерә. Бу аңа гайре табигый хәл булып тоела. Шуңа күрә, аның яшь, матур һәм көчле чаклары шөкер итмичә, рәхмәт әйтмичә уза.

Олыгайгач, киресенчә икән. Кояшның түбәнәюен дә, шәүләңнең озынаюын да сизмисең бит инде. Барысы да элеккечәдер, берни дә үзгәрмәгәндер кебек тоела. Олыгаю да шулай килә. Үзеңне элеккедәй тоеп, нәрсәнедер күтәрергә маташып карыйсың – килеп чыкмый. «Һи, мин бу эшне өч минутта эшләп ташлыйм», – дип тотынганың өч көнгә сузыла.

Бәхеткә, адәм баласы барысына да күнегә. Син дә күнегәсең. Ямьсезлегеңә дә күз өйрәнә, авыруларга да, хәлсезлеккә дә. Хәзер инде үз көчеңне чамалап кына тотынасың. Теләкләрнең дә, хыялларның да үзең күтәреп йөртерлеген генә калдырасың.

Картлык шөкер итеп яшәү өчен искиткеч шәп шартлар тудыра икән. Көн дә сызлаган аяк-куларың берәр сәгать кенә тынып торса, бу – могҗиза. Аллага шөкер! Нәрсәдер эшли алуың, шуңа шөкер итә алуың, хәтта сулыш алуың – бәхет.

Әйтеп кенә бактым

«Кемсыңыл»

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Безнең якта сөйләм теле шактый үзгә. Сүзләрне, интонацияне бераз гына үзгәртеп, әйтәсен гади генә итеп әйтүләр дә бирәләр.

Илдус – аю кебек зур гәүдәле егет, шуңа күрә аңа «Аю» кушаматы тагылу табигый. Ә хатыны Мөршидә бик бәләкәй, юка гәүдәле, җил катырак исеп куйса, очар да китәр төсле. Шуңа карамастан авылда, Аю Илдусы хатынына ышыкланып яши икән, Мөршидәдән коты оча икән, дигән сүзләр йөри. Кайвакыт авыл егетләре: «Әнә хатының килә», – дип, аны куркытмакчы да булалар, ә Аю Илдусы сер бирми, өстән аска карап, эре генә итеп: «Килсә ни, кем соң ыл», – дип кенә куя. Кешечә, дөрес итеп: «Кем соң ул», – дими, авызын иренеп кенә ача, иреннәрен бераз чалшайта да, авыз кырыенда калган кечкенә генә ярыктан сүзләрне җәлләп, кысып-кысып кына чыгара. Янәсе, сезгә тел әрәм итеп тормыйм әле.

Авыл егетләре аның турында төрле имеш-мимешләр дә тараткалыйлар. Мәсәлән: «Беркөнне Мөршидә Аюын тотып ярган икән...» кебек сүзләр тарату алар өчен берни дә тормый. Бу сүзләр Илдуска да барып җитми калмый, әлбәттә. Ә ул һәрвакыттагыча иреннәрен чалшайта да: «Мине тотып ярырга кем сың ыл», – дип кенә куя. Аның бу сүзләре инде «Аю» кушаматын кысрыклап чыгарган да кушаматка әйләнгән. Ягъни «Кемсыңыл» дисәләр, кем турыда сүз барганын бөтен авыл белә.

Соңгы араларда аның турында ың-шың ишетелми башлады. Баксаң, егетебез, контракт төзеп, махсус хәрби операциягә киткән булган икән. Әйтүләренчә: «Башкалар китә, алар кем сың? Мин кемнән ким?» – дигән дә, Мөршидәсен кочаклап үпкән, көтәргә кушып киткән дә барган ди. Үзе булмагач, аның турында имеш-мимешләр дә тукталып калды. Әмма беркөнне авыл янә ду килә башлаган. Күкрәгенә медальләр тагып, авылга «Кемсыңыл» кайтып кергән. Мин үзен күрмәгән идем әле, тик озынколак хәбәрләргә караганда, яраларым төзәлгәч, тагын китәм, дип әйткән ди. Ә Мөршидәсе каршы икән. «Анда япа-ялгызыңны җибәрергә мин җүләр түгел», – ди. Әле сүзләренә өстәп: «Китсәң, мине дә алып кит, я булмаса салкын дәрья суларына салып кит», – дип җырлап та куя, имеш. Әлбәттә, монысы – чыннан да, имеш-мимеш инде, авыл халкы үзеннән өстәп сөйләргә бик ярата бит ул, ә «Кемсыңыл» һәрвакыттагыча аз сүзле, иреннәрен чалшайтып, бераз киная белән көлемсерәп кенә сөйләшер. Медальләре турында сораша башлагач та: «Бирделәр инде», – диюдән артыгын әйтмәс. Нинди батырлыклар күрсәтүе турында да җәелеп китеп сөйләмәс.

Бер дустым: «Ир кеше күкрәгенең бер ягында – куян, икенче ягында арыслан ятар, кайсын уятасың бит!» – дияргә ярата иде. Ә Илдусның күкрәгендә куянга урын булмагандыр. Аңа арыслан гына сыйгандыр дип уйлыйм. Аның белән очрашып, бераз гына сөйләшеп утырган идек. «Гел алгы сызыкта йөргәнсең, бик куркыныч булмадымы?» – дип сорагач та, иреннәрен бераз чалшайтып: «Куркырга, кемсың алар», – дип кенә куйды.

– Дәваланып аякка баскач, тагын китәргә җыенасың икән.

– Мөршидә нәрсә дияр бит.

Шулай диде дә, ихлас күңелдән көлеп җибәрде. Аңа Мөршидә белән мин дә кушылдык. Җитди, куркыныч нәрсәләр турында сөйләшсәк тә, күңелләрдә нindидер бер рәхәтлек, җиңеллек хисе бар кебек иде. Безнең татар юкка гына: «Кайгыларга баш имә, кайгыларга башың исән, рәхәт яшәрмен димә», – дип җырламый шул.

Иң авыр чакларда да уен-көлке кыстырып сөйләшә белү – үзе бер батырлык дип уйлыйм. Героем «Кемсыңыл» да шундыйлардан.

ЯҢА ЯКЫН КӨНЧЫГЫШ НИ ВӘГЪДӘ ИТӘ?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Даими укучылар хәтерли торгандыр: һәр Яңа елга фараз язганда, без кешелек җәмгыяте өчен мөһим вакыйгаларның Якын Көнчыгыштан башланасын искәрттек.

2020 елга фаразда: «Киеренкелек Якын Көнчыгыш сызыгы буйлап күчәячәк... Зур дәүләтләрнең низаглары «кара алтын»лы мөселман дөньясындагы вазгыятькә тыкшыну рәвешендә барыр, мөгаен», – дигәнбез. 2023 фаразында исә: «Бар ислам дөньясында тектоник плитәләрнең көчле хәрәкәте көтелә, әмма хәлиткеч вакыйгаларның кайчан буласын төгәл әйтә алмыйбыз. 2023 ел чигендә үк булмаска да мөмкин. Әмма бер нәрсә бар: ислам дөньясындагы үзгәрешләр бөтен дөньяга нык тәэсир итәчәк. Россиягә аеруча», – дигәнбез.

Без язган фаразларның фальстарты бүген Фәләстыйнда булып ята. Үткән атнаның шимбәсендә Газзә секторында бар кешене шаккатырган хәл булды: ХАМАС сугышчылары Израиль Газзә чигенә корган «акыллы стена»ны җимереп, сиончылар оккупациясендәге Фәләстыйн шәһәрләрен яулап алды, байтак тотыклар кулга төшерелде. Һөҗүм һавадан да, диңгездән дә, коры җирдән дә барды. Парапланнар һәм дельтапланнарга утырган гыйсъянчыларның җиргә төшеп утыруларын сурәтләгән видеоларны теләгән кеше интернеттан таба ала.

Бер нәрсәне искәртик: Израильнең регуляр армиясендә 176,5 мең кеше хезмәт итә. Израиль чыганаклары беренче сәгатьләрдә ХАМАСның өч йөз сугышчысы бәреп керде дип хәбәр итте, аннан соң аларның саны 2 меңгә җиткән. Фәләстыйнлылар бернинди каршылык күрмичә диярлек, 40–50 километрдан артык юл үтеп, Газзәне Иордан елгасының көнбатыш яры белән тоташтыра яздылар. Дөньядагы иң яхшылардан дип саналган «Меркава» танклары яндырылды һәм трофей итеп алынды. Гыйсъянчылар яулап алынган шәһәрләрне кулда тотуны максат итеп куя алмый иде. Партизаннар сугышы күз алдында тотылды.

Без сугыш хәрәкәтләре турында тәфсилләп сөйләргә җыенмыйбыз. Шимбә һөҗүме барлык сәяси көчләр тарафыннан да «тарихта тиңе күрелмәгән» дип бәяләнде. Чик буендагы «акыллы стена» беркем дә үтә алмаслык дип санала. Ул хәтта җир астында да бар, туннель казып та үтә алмыйсың. Алдагы елларда шунда хезмәт иткән гыйбри солдатлары «аңа кош та якыная алмый» дип белдерделәр һәм ХАМАС сугышчыларының үтеп керүе махсус оештырылды дигән фикерне алга сөрәләр.

ХАМАС һөҗүмнең башында ук үз сугышчыларына тыныч халыкка кагылмаска әмер бирелүен игълан итте. Әмма нәкъ менә шунда – хатын-кызларны һәм балаларны вәхшиләрчә үтерүдә гаепләнде дә. Урын аз булганлыктан, без гаепләүләрнең берсен генә китерәбез. Израильнең тәүлек буе эшләүче халыкара i24 News телеканалы сишәмбе көнне фәләстыйнлылар кырык баланың башын кисеп үтерде дигән репортаж эшләп таратты. Репортаж дигәч, сез уйлый күрмәгез тагын: анда бер баланың да мәете күрсәтелмәде. Әмма бу дөньякүләм шау-шу таратты. Байден ХАМАСны «балалар үтерүче» дип атады, Байден администрациясе вәкиле Джон Кирби телеэфирда күз яшьләрен чак тыеп торды. Дөрес, соңыннан физиогномистлар фаш итте: Кирби камерага уйнады, диделәр. Төрекләрнең «Анадолу» мәгълүмат агентлыгы булмаса, башы киселгән кырык бала фәләстыйнлыларга ягылып кала иде. Әмма «Анадолу» журналистлары ЦАХАЛ (Израиль армиясе) җитәкчелеге белән элемтәгә керде. Генераллар исә андый факт булмавын раслады. Репортажны эшләгән журналист хатын-кыз да танырга мәҗбүр булды: ул бер баланың да мәетен күрмәгән. Автор бу юлларны язганда, мөселманнарга дошман булган бик күп чыганаклар «репортаж»ның фейк булуын таныды. Бик күп шундый башка фейклар да фаш ителде. Гыйсъянчыларның рәхимсезлеген раслаган аз санлы кайбер фактлар булуы ихтимал. Бар кешене дә контрольгә алып булмый, сугыш – рәхимсез эш.

Фейклар таратуның максаты исә сиончыларның рәхимсез рәвештә Газзә секторын утка тотып, җир белән тигезләвен аклау һәм гыйбри солдатларының «кулын чишеп», һәртөрле ерткычлыкка рөхсәт бирү иде. Израильнең оборона министры Йоав Галант: «Без сугыш алып баруның барлык кагыйдәләрен гамәлдән чыгардык. Безнең солдатлар бер нәрсә өчен дә җавап тотмаячак. Хәрби судлар булмаячак», – диде. «Яңа Газзәдә бернинди йорт та булмаячак, бары тик палаткалар гына», – дигән сүзләр дә шуныкы. Гыйбриләргә тыныч халыкны үтерергә дә, таларга да, көчләргә дә ярый дигән фикер ачыктан-ачык әйтелә башлады. Газзә секторына ут һәм су бирү туктатылды, Мисырдан килүче гуманитар ярдәм машиналары, Тель-Авив бомбага тоту белән янагач, кире борылды. Димәк, 2,5 миллионлап кеше бомбага тотулардан исән калса, ачлыктан һәм авырулардан үлеп бетәргә тиеш. Аларны кешегә санамыйлар.

Израиль коры җирдән дә Газзәгә бәреп керергә җыена. Бу юллар язылганда, коры җир операциясе башлану алдында. Резервтагы 360 мең сугышчы армиягә чакырылды. ЦАХАЛның 2,5 миллион сугышка яраклы резервы бар. Израиль армиясендә хатын-кызлар да хезмәт итә. ХАМАС коралллы көчләре 40 мең кешедән тора, тагын ун меңләп башка төркем сугышчылар бар. Көчләр чагыштырмасы ни дәрәҗәдә тигез түгеллеге калькуляторсыз да күренә. Заманча коралланган, ни теләсә, шуны эшләргә рөхсәт ителгән сугышчыларның бомбага тотылганнан соң айный алмаган халык өстенә килеп керүен күз алдына китерә аласыздыр.

Ни өчен Израиль ачыктан-ачык геноцидны бөтендөнья җәмәгатьчелеге күз алдында шулай җиңел генә эшли ала? АКШның тиңсез яклавыннан файдалана. Сугышның беренче сәгатьләрендә үк Тель-Авив Вашингтоннан хәрби ярдәм сорады һәм ярдәм кичекмәстән юлга чыкты һәм килеп тә җитте. АКШның «Джеральд Форд» очкыч йөртүче корабы һөҗүм итүче кораблар төркеме белән Урта диңгездә һәм Газзәгә ярдәм күрсәтергә теләүче мөселман илләренә сугыш белән яный. Тагын бер шундый төркем юлга чыгачак, диделәр. Очкыч йөртүче кораблар экипажы гына да якынча 5 мең кешедән тора.

Израиль оештыра башлаган вәхшәт ризасызлык уятмый кала алмый. Төркия башлыгы Рәҗип Әрдоган, фәләстыйнлыларның гуманитар хокукы бозыла, дип тавыш кубарды. Тыныч халыкны судан һәм электрдан, азык-төлектән өзү халыкара хокук нормаларын боза. Шундый ук белдерүне БМО Генераль секретаре да ясады. Немец язучысы Юдит Мейер: «Сез Израиль тарафыннан коралсыз журналистлар, табиблар һәм балалар үтерелүен гаепләмисез икән, хәзер ХАМАСны да гаепләргә кирәкми. Женева конвенциясе тарафыннан каралган хәрби җинаятьләр өчен җаваплылык һәркемгә мәҗбүри», – дип белдерде. Намусы уянучылар гыйбриләрнең үз арасында да байтак. Израиль парламенты әгъзасы Офер Кассиф: «Хөкүмәт фәләстыйнлыларга карата геноцид кыла», – дип чыгыш ясады. Европа хакимиятләрендә дә карашлар үзгәрү ягына авыша. Сиончыларга бүген тиңе күрелмәгән вәхшәт оештырырга юл куелса, Җир шары күләмендә явызлыкка юл ачылачак. Алар, Якын Көнчыгышның йөзен үзгәртәбез, дип тотындылар. Ул, чынлап та, үзгәрәчәк, әмма озак сроклы перспективада алар теләгәннең нәкъ киресе килеп чыгачак. Бөек үзгәрешләрнең увертюрасын гыйбриләр уйный, әмма төп өлештә бөтенләй башка көчләр мәйданны яулаячак.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҖИР КЕШЕСЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә



Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәрен «Казан Экспо» үзәгендә зурладылар. Кыр батырлары, уңган терлекчеләр, хуҗалык җитәкчеләре, агросәнәгатьнең төрле тармакларындагы тырыш кешеләргә рәхмәт сүзен җиткерергә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев килде.

– Бу – туган җирен ихлас яратучы, хезмәт сөючеләр бәйрәме. Сез тырышып эшләгәнгә күрә, халыкның табыннарында һәрвакыт икмәк, ит, сөт һәм яшелчәләр бар. Быелгы ел авыл хуҗалыгы өчен җиңел булмады. Шуңа карамастан, лаеклы уңыш җыеп алынды. Басулардан 3,5 млн тонна ашлык кайтты, 1,5 тонна шикәр чөгендере, 790 мең тонна бәрәңге, 250 мең тонна яшелчә җыеп алырга ниятлибез, терлекләргә җитәрлек күләмдә азык әзерли алдык. Сезнең һәр кайсыгыз бу эшкә зур өлеш кертте. Игелекле, тырыш хезмәтегез өчен зур рәхмәт! – диде Рөстәм Миңнеханов.

Быел иң күп иген уңышын Тәтеш (179 мең тонна), Буа (165 мең тонна), Арча (159 мең тонна) районнарында җыеп алдылар. Уңдырышлылык буенча Тәтеш, Чүпрәле, Кукмара һәм Кама Тамагына тиңнәр юк. Сөт буенча Кукмара, Әтнә, Балтач, Саба районнары алда бара. Мамадыш һәм Тукайда итне күп җитештерәләр. Татарстан Рәисе алдынгы хуҗалыклар, фермерлар, механизаторлар, терлекчеләрне аерым телгә алды һәм рәхмәт әйтте.

– Безнең бурыч – авыл кешесенә заманча, уңайлы тормыш шартлары булдыру. Республикада территорияләрне комплекслы үстерүне күздә тоткан 44 программа эшли, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Тантанада республиканың авыл хуҗалыгы үсешенә зур өлеш керткән кешеләрне бүләкләделәр. Кукмара районының Вахитов исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе Нәфыйк Хөсәеновның түшенә «Дуслык» ордены тактылар.

Нәфыйк ХӨСӘЕНОВ

Вазыйфасы һәм эшләгән урыны: Вахитов исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе. (Кукмара районы)
Хезмәт стажы: 43 ел.

:: Ни өчен авыл?
– Аны бөтен җаным белән ятратканга күрә. Әле дә авылдан китсәм, ике-өч көннән сагына башлыйм. Җирен дә, һавасын да, табигатен дә. Авылда рәхәтләнеп күкрәк тутырып сулап була. Кая барсаң да, таныш йөзләр, үз кешеләр.

:: Эшегездә нәрсә рухландыра?
– Эшнең дөрес оештырылып, тәртип белән баруы. Бездә халык аз гына яңгыр яумаса да, зарлана башлый. Ләкин быел да зарланырлык бер сәбәп тә күрмим. Яңгыр булмаса да, узган елдан калган дым, яңа технологияләр, көчле техника белән елны матур гына чыктык. Ашлыгын да, терлек азыгын да хуҗалыкка да, халыкка да җитәрлек әзерли алдык.

:: Җир кешесенә хөрмәт җитәрлекме?
– Әлегә зарланып булмый, эшләгәнне күрәләр. Төпләнеп эшләгәнгә күрә, нәтиҗәсе дә, күрсәткече дә бар. Кешеләр белән дә уртак тел табып эшлибез. Шуңа күрә эшебез дә яхшы барадыр, дип уйлыйм. Кешенекеннән ким булса, борчылабыз. Күрше районнардан, колхозлардан калышасы килми дип, ак күңелләшү белән үҗәтләнеп эшлибез. Үземә әле генә Россиянең «Дуслык» орденын бирделәр. Җир кешесенә хөрмәт шуннан да күренә инде.

:: Күңелегезне нәрсә төшерә?
– Авыл хуҗалыгында иткә, сөткә, ашлыкка яхшы бәя булса, безгә башка берни кирәкми. Кешегә яхшы хезмәт хаклары биреп, яшәр өчен матур шартлар тудырсак, авылдан кеше дә китмәс. Безнең төбәктә бу яктан зарланып булмый.

Илүзә ШӘРӘФИЕВА

Вазыйфасы һәм эшләгән урыны:
«Шыгай» фермасы терлекчесе (Апас районы).
Хезмәт стажы: 34 ел.

:: Ни өчен авыл?
– Шәһәргә дә китеп карадым, ләкин аннан тиз әйләнеп кайттым. Олы бала буларак, аннан кайтуга ук, колхозга эшкә чыктым. Шуннан бирле гел ферма тирәсендә: таналар карадым, үгезләр симерттем, терлекләргә азык бирүне дә контрольдә тоттым. Иремнең төп нигезендә яшибез. Абзар тутырып мал-туар асрыйбыз. Кая монда шәһәр турында уйлау?!

:: Эшегездә нәрсә рухландыра?
– Соңгы ун елда яңа туган бозаулар карыйм. Ике кешегә 100–160лап тирәсе бозавыбыз бар. Аларны 4–5 айга кадәр үстереп бирәбез. Бик җаваплы эш. Бозауларны бала караган кебек тәрбиялибез. Көндез туса да, төнлә туса да, вакытында угызын эчерергә кирәк. Авырсалар, җитлекми яки авыру тусалар, борчылам, әлбәттә. Үземнең эш тәҗрибәмдә борынсыз, ярты авыз белән туган бозау да булды. Аны да кадерләп үстереп, исән-сау озаттык. Аяклары кәкре туганнары да бар. Аларын да яхшылап карыйбыз. Әле менә шушы көннәрдә бер бозавыбыз җитлекми туды. Бик кечкенә инде. Өйгә кайткач та истән чыкмый бит, эш вакыты булмаса да, барып, хәлен белеп кайттым. Ирем дә: «Шул фермадан кайтмыйсың инде», – дип сүгә. Балалар үскәнен дә күрми калдым.

:: Җир кешесенә хөрмәт җитәрлекме?
– Бар! Хөрмәт булмаса, болай очынып эшләп йөреп булыр идеме икән? Безгә инде күп тә кирәкми. Диплом-медальләр, министрлыкның мактау грамоталарын да бирделәр. Җитәкчеләрнең мактау сүзләрен ишетү дә үсендерә. Әле менә кичә генә «Татарстанның атказанган терлекчесе» исемен бирделәр. Соңгы берничә елда хезмәт хаклары бик күтәрелде. Бозауларны исән-сау тәрбияләгәнгә, акчаны да яхшы алабыз.

:: Күңелегезне нәрсә төшерә?
– Фермалар бету. Күрше-тирә авылларда бер ферма да калмады, барысы да безгә килеп эшли. Зур авылларда да фермаларның ишекләренә кадак кагылды. Безнеке дә тора-бара барыбер бетәр инде, дип борчылабыз. Быел терлек азыгын да азрак салдылар. Әлегә сөенә-сөенә эшкә йөрибез, эшсез калсак нишләрбез? Быел мәктәпне яптылар, яшьләр юк. Безнең буын – фермада соңгы могиканнар.

Наил КАСЫЙМОВ

Вазыйфасы һәм эшләгән урыны:
«Алан» җәмгыяте механизаторы (Теләче районы).
Хезмәт стажы: 45 ел.

:: Ни өчен авыл?
– Аланда тудым, Аланда үстем, гомер буе шушында хезмәт иттем. Безнең заманда бар кеше дә диярлек авылда кала иде. Ләкин хәзер дә мин шәһәрне түгел, авылны сайлар идем. Башка тормышны күз алдына да китермим.

:: Эшегездә нәрсә рухландыра?
– Кайда трактор хезмәте кирәк – мин шунда. Шуңа күрә мине тракторның ватылмыйча эшләве дә сөендерә.

:: Җир кешесенә хөрмәт җитәрлекме?
– Эшләгән кешегә җитә. Авыл хуҗалыгында хөрмәтне эшләп кенә казанып була. Техниканы карасаң, эшеңдә тәртип булса, бәялиләр. Мин булганыннан канәгать, иң мөһиме саулык булсын. Эшләү дәверендә диплом-бүләкләрен дә, атказанган исемнәрен дә алдык. Хезмәт хакының артыгын бирә дә алмыйлар, чөнки без җитештергән продукциянең бәясе юк бит. Сөт бәяләре төште, нәтиҗәдә авылларда сыерларны иткә җибәрә башладылар.

:: Күңелегезне нәрсә төшерә?
– Авыл хуҗалыгында яшьләр калмый. Эшчеләрне читтән эзлиләр бит. Бәлки, яшьләрне йортлар салып җәлеп итәргә кирәктер? Торыр урыны хәл ителеп, бер төпләнеп калган кешенең, бәлки, кабат шәһәргә чыгып китәсе килмәс иде? Хезмәт хакын күтәрми торып, хезмәт кешесенең хәле үзгәрмәячәк.

Мансур ШӘЙХЕТДИНОВ

Вазыйфасы һәм эшләгән урыны:
«Олы Кариле» җәмгыятендә агроном (Кама Тамагы районы).
Хезмәт стажы: 46 ел.

:: Ни өчен авыл?
– Без яшь чакта тракторчы, шофер булу дәрәҗәле хезмәт иде. 10 сыйныфны бетергәндә үк тракторчы-машинист таныклыгын алдык, шунда ук эшли дә башладык. Коммунизм төзибез, дип ялкынланып эшләгән «юләр» чаклар. Ул еллардан соң дөньялар йөзгә тәрләнде, хәзер инде авылда яшәү үзе бер рәхәт. Газы, юлы бар, техника үзгәрде, кул хезмәте бетте.

:: Эшегездә нәрсә рухландыра?
– Быелгы уңыш тыйнак булды. Шулай да уҗымнардан – гектарыннан 30 центнер, язгы культуралардан 20 центнер җыеп ала алдык. Чәчкән, тырышканның нәтиҗәсен күрү күңелне күтәрә.

:: Җир кешесенә хөрмәт җитәрлекме?
– Хезмәтне күрәләр, зарланып булмый.

:: Күңелегезне нәрсә төшерә?
– Крестьянны аны һәрвакыт: «Бүген булмаса, иртәгә булыр», – дигән өмет яшәтә. Авыл хуҗалыгында түләү әллә ни юк, чөнки продукциясенең бәясе начар. Аннан соң бәяләр аермасы зур булу күңелне кыра. Ягулык, техника хаклары әллә ничә тапкыр артса да, яхшы ашлык бәясе һаман да шул 10 сум килеш тора.

ТАТАР КОНТЕНТЫ, МИЛЛИ ПРОЕКТЛАР, ТАТАРЧА КӨНЛӘШҮ

ЯШӘҮ МОХИТЕНДӘ МИЛЛИЛЕКНЕ НИЧЕК БУЛДЫРЫРГА?

Милли бушлык. «Ватаным Татарстан» редакциясе каршында оешкан «Туган тел» клубының беренче очрашуында шул хакта фикер алыштык. Катнашучылар аның тәэсире турында уйланды һәм бу проблеманы хәл итү юлларын эзләде. «Түгәрәк өстәл»дә Казан Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл СӘГЫЙТОВА, Татарстан мәдәният министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән арадашлык бүлеге җитәкчесе Айрат ФӘЙЗРАХМАНОВ, «Sabamendare» остаханәсе осталары, милли дизайнерлар Лилия, Фәрит ВАФИНнар, шагыйрә Резедә ГОБӘЕВА, журналист Альберт ШАКИРОВ катнашты. «Түгәрәк өстәл»не «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Гөлнара САБИРОВА алып барды. Игътибарыгызга әлеге очрашуда яңгыраган төп фикерләрне җыеп бирәбез.

:: Соңгы елларда милли бушлык артамы, кимиме? Аның йогынтысы ни дәрәҗәдә?

Гүзәл СӘГЫЙТОВА:
– Без үзебез тудырган нинди дә бер мохиттә яшибез. Шуңа мин Казан мэриясе оештырган, милли мохиткә бәйле проектларның барысына да, әйтик, «Хәрәкәттә – бәрәкәт»кә барып, халык кәефен белешәм. Кемнәр йөри, яшьләр бармы, күпме, бу чаралар турында нәрсә уйлыйлар, файдасын күрәләрме – миңа боларны үзем күреп, үзем төшенү мөһим. Проект без өметләнгәннән дә яхшырак булып чыкты. Проект барган көннәрдә Кабан күле буена бөтен Казан җыелган һәм без барыбыз да бер Казанда кайныйбыз, барыбыз да туган телдә аралашабыз кебек. Әмма чынбарлык икенче төрлерәк. Әнә шул чынбарлыкны уңай якка үзгәртү өчен, шушындый проектлар күбрәк кирәк. Ул татар телен популярлаштыра, мәдәниятне, фольклорны саклап калуга уңай йогынты ясый. Самарадан килгән бер апа, мәсәлән: «Без Самарада үзебезнең биюне оныттык, ә сез Казанда халыкка Самара биюен өйрәтәсез», – дип елый-елый рәхмәтен әйтте. Казан Башкарма комитетында эшли башлагач, «Яшьләргә нинди проектлар кирәк, алар нәрсә белән кызыксына, телне, милли үзенчәлекне саклау җәһәтеннән нәрсә эшләп була?» дигән сорауларга җавап эзләп, «түгәрәк өстәл»ләр үткәрдек, тәкъдимнәр җыйдык. Бу проектлар – шуның нәтиҗәсе. Башка милләтләр белән дә эшлибез. Әлеге проектларның үзенчәлеге шул: һәр чара туган телдә алып барыла. Бушлыкны менә шушылай тутырып була, миңа калса. Фикерләү рәвешен үзгәртеп. Милли үзаңны күтәреп. Әле менә шушы арада гына безнең янга башка төбәктән журналистлар килде. Казанда татарча оялмыйча сөйләшкәнгә игътибар иткәннәр. Ә бит күп җирдә туган телне, бу – авыллык, шәһәрләшкәч, русча сөйләшергә кирәк, дип кимсетү бар.

:: Милли проектлар белән телгә мәхәббәт уятып буламы?

Айрат ФӘЙЗРАХМАНОВ:
– Туган телгә мәхәббәт уятып буладыр, әмма без көткән нәтиҗә булырмы? Бу сорау ачык кала. Әйе, Татарстан Республикасында телгә кагылышлы ике зур программа бар. Аның берсе – дәүләт телләре программасы, икенчесе – татар милләтенең этник үзенчәлекләрен үстерү программасы. Әмма программа ул – план, ә стратегия – проблеманы барлап, фәнни нигездә хәл итү юлларын күрсәтү. Безгә әнә шул стратегия җитми. Стратегик эш дөнья күләмендәге тәҗрибәләрне өйрәнеп алып барыла. Ник дигәндә, татар теле проблемасы башка телләрнекенә охшаш. Шулай булгач, Европа тәҗрибәсеннән дә йөз чөерергә кирәкмидер. Мондагы кешеләр, без, бары фикер генә җиткерә алабыз. Ә проблеманы хәл итү юлларын галимнәр аныкларга тиеш. «ВТ»да бу темага язма чыга икән, аңа галимнәр бәя бирергә тиеш.

Телгә мәхәббәтне балачактан тәрбияләргә кирәк. «Апуш» балалар театры – моның иң үтемле чарасы. Хәзер аның филиаллары да шактый. Димәк, «Апуш» көчле хәрәкәткә әйләнеп бара. Ләкин, театр – телне өйрәнүнең бер факультатив чарасы гына. Ә телне саклауда төп чара – мәктәпләр. Мин үзем – Казанда авылсыз, әби-бабайларсыз үскән бала. Шуңа күрә татар телен ул кадәр үк камил белмим. Хәзер телне саклауда «Адымнар» мәктәбен, Казанның 2 нче гимназиясен үрнәк итеп куярга мөмкиндер. Мондый мәктәпләр һәрбер районда булса иде. Татар мәктәпләре турында әти-әниләр белеп торырга тиеш. Чөнки алар бик аз дигән фикер таралган.

:: Милли үзаң һәм телне белү – алар ни дәрәҗәдә тәңгәл? Без бары тик татарча сөйләшкән кешене генә татар дип атый алабызмы? Әллә татарча белмәгән, әмма милли үзаңлы кешене дә татар дип үстерергә тиешбезме?

Лилия ВАФИНА:
– Без ирем белән – «Sabamendare» остаханәсе хуҗалары. Мин – Саба кызы, ә ирем Фәрит Казанда үскән, рус мәктәбендә укыган, татарча сөйләшми торган бер егет иде. Хәзерге көндә ул – мин русча сөйләшкәндә дә, татарча җавап бирә торган кеше. Димәк, кешенең күңелендә була икән, нинди генә мохиттә үссә, формалашса да, туган телен өйрәнәчәк. Ул гомер буе полициядә эшләде, лаеклы ялга киткәч, милли мохит турында уйлана башлады. Аның ни дәрәҗәдә татар җанлы кеше булуы безнең эшебездә чагыла. Чигәбез, тегәбез, милли мендәрләр, киемнәр әзерлибез. Ә мин балалар бакчасында 18 ел буе өлкән тәрбияче булып эшләдем. Бу тема миңа бик якын. Балалар бакчасына балалар киләләр, без «әти», «әни» дип өйрәтә башлыйбыз. Районның 93 проценты татар, аралашу гел татарча. Әмма... Бакчадан китү белән, бала телдән читләшә башлый. Чөнки әтиәни балага татар теле кирәкми, русча сөйләшергә кирәк дип, тәрбияне икенче якка бора. Без бу хакта гел уйланабыз һәм шундый фикергә килдек. Тел яшәсен өчен аның модалы, яшьләр арасында популяр булуы кирәк. Шуңа остаханәдә кичләрен яшьләрне җыеп, татарча аралаштырырга тырышабыз. Бу – безнең телне популярлаштыруга кечкенә генә өлешебез.

Фәрит ВАФИН:
– Татар кем ул: татар телен белүчеме, әллә татар мохитен үстерүгә өлеш кертүчеме? Телне белү беренче урындамы, әллә калебең белән милли җанатар булу мөһимрәкме? Мәсәлән, мин – татарча авыр сөйләшүче, җаны-тәне белән татар дип җан атучы кеше. Безгә милли бизәкле җиһазлар, шул ук мендәрләр, кием-салым, аксессуарлар бик ошый. Һәм без аны модага кертергә тырышабыз. Татар теле – бик матур тел, бай тел. Һәм ул да «модный» булырга тиеш. Инде татар телен өйрәнү турында. Татарча уйлый башлагач кына, мин татарча сөйләшә башладым. Башта фикерләү барышы үзгәрде.

Тел өйрәнү өчен башта ихтыяҗ тудырырга кирәк. Ул телне модага керткәндә генә туа. Ә инде без белергә тиеш, өйрәнергә тиеш дигән фикер, мәҗбүриләү эшләмәячәк. Авылларда нишләп татарчадан ваз кичәләр, дисез? Чөнки аларга рус теле «модный» тоела. Телне стратегик план төземичә генә модага кертеп булмаячак. Ул план тормышның бөтен өлкәсен колачлар иде. Әйтик, без «КамАЗ» машиналарын төзибез. Ә нишләп шул машина кузовына татарча орнамент кертмәскә? Яңа бина төзелә, фасадына татарча орнамент өстәргә кирәк. Мәктәп формасына да татар элементын өстәргә була. Аңа әллә нәрсә дә кирәкми: ир бала костюмын озынрак итеп тегәсе, кыз бала киемен дә бердәр элемент белән бизәргә яки чулпы тәкъдим итәргә була.

Айрат ФӘЙЗРАХМАНОВ:
– Монда «мода» сүзе күп яңгырады. Бу тел статусына бәйле. Казанда хәзерге вакытта телгә мөнәсәбәт яхшы, хәтта мода да бар. Әйе, Казан – аерым дөнья. Саба, Кукмара, Актаныш, Мөслим, башкалар да – аерым дөньялар. Миңа калса, Актаныште телгә мода бар. Ә ни өчен башка районнарда ул мода түгел – моны өйрәнергә кирәк. Географик яктан гына түгел, яшь төркемнәрен дә аерым-аерым өйрәнергә иде.

Идар Мөхәммәтҗанов

Һәр халыкта башта элита формалаша. Әмма аннан башка да адымнар бар, ул тәҗрибәләрне өйрәнергә, карарга кирәк. Вак-вак адымнар белән төрле бушлыкларны тутырсак, алга китеш булачак. Әйтик, Чечняда, Якутиядә тел статусы бик югары. Аларда туган телеңне белмисең икән, синең статусың да түбәнрәк.

Альберт ШАКИРОВ:
– Татар телен киләчәккә нинди хәлдә тапшырачакбыз – бу җаваплылык безнең буын өстендә. Әле без соңгы ноктага җитмәдек: телнең кулланылышы, аның мохите алга таба да тараячак. Моны факт буларак кабул итәргә кирәк. Авылларның рус теленә күчүе шаккатырса да... Әтнә районында балалар русча сөйләшсеннәр инде! Гәрчә бу районда рус авылы булмаса да. Димәк, татар теленең кирәген тапмыйлар. Рус авылы булмаса, анда интернет бар. Ә анда татарча контент булса да, кызыктырырлык түгел. Шуңа күрә без ул ихтыяҗны тудыра алмыйбыз, ә мохитне шул ук проектлар ярдәмендә тудырырга була. Телне «рафинированный» хәлдә булса да киләчәккә тапшырып була. Аның өчен әдәби тел үрнәкләрен Фоат Галимуллин, Илдар Кыямов чыгышларын кинохроника, аудиохроника рәвешендә сакларга һәм таратырга кирәк. Бу эталон була. Миңа калса, аска тәгәрәүдән соң өскә күтәрелеш булачак. Бу вакытка безнең материал әзер булырга тиеш. Тел комиссиясенә бу уңайдан бер фикер: интернетта эшләүче журналистлар, блогерлар проектларына акча бүлеп бирүне караган вакытта, аның нәтиҗәлелегенә, шул ук караулар санына игътибар итмәскә. Интернетта татар мохите булмагач, ул проектларның да караулар саны зур булмаячак. Алар конкурстан тыш булырга тиеш.

:: Киләчәк өметле булсын өчен нишләргә?

Альберт ШАКИРОВ:
– Татар халкы, татар теле саклансын өчен, татар кешесе бай булырга һәм үзе тотынган эшне җиренә җиткереп эшләргә тиеш. XX гасырда татар меценатлары, татар байларының мәгариф һәм матбугат системасын тотуы – моңа үрнәк. Шул дәрәҗәгә, һич югы яртысына гына булса да әйләнеп кайта алсак, киләчәктә өмет бар. Механизмнар, стратегияләр әлбәттә кирәк. Ләкин халыктагы пассионарлык та кирәк. Ә ул аерым шәхесләргә бәйле. Пассионарлык бик бар, әмма кесә ягы такыр.

Гүзәл СӘГЫЙТОВА:
– Бала күңеленә гаиләдә милли оеткы салынамы, юкмы – алдагы адымнар шуңа бәйле. Әмма без – хәзер шундый эти-әниләр: баланы күрмибез дә диярлек. Шуңа күрә бакчада баланың милли үзаңы формалаша, ныгый. Аннан ул «Апуш – нәниләр» театрына китә. Аннан мәктәп. Шушы һәрбер этапта бала милли даирәгә эләксә, ниндидер өмет була. Тагын шунысы да бар: һәрбер этапта өмет шәхескә бәйле. Әйтик, мәктәптә директор татар җанлы булса, анда милли мохит була. Без исә шушы мохитне тудыруда кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышачакбыз.

Резедә ГОБӘЕВА:
– Бер үк гаиләдә тәрбияләнгән балаларның да тел белү дәрәҗәсе ике төрле. Мин моны үз балаларымнан чыгып әйтәм. Монда күп нәрсә мохиткә бәйле. Миңа калса, милли бушлыкны мохит тудырып кына тутырып була.

Фәрит ВАФИН:
– Татар халкында яхшы мәгънәдә көнләшү бар. Күршенең йорты бер катлы булса, минеке ике катлы булырга тиеш, капкам күршенекеннән ярты метрга гына булса да биегрәк булырга тиеш, мәсәлән. Бик яхшы сыйфат бу. Шуны ничек тә тел файдасына борырга иде. Әйтик, ул татарча сөйләшә, нишләп мин татарча сөйләшмәскә тиеш?

Гөлинә ГЫЙМАДОВА әзерләде

Фикер



Чулпан ГАРИФУЛЛИНА:
– Киләчәккә планнар корганда, 18–30 яшьлекләр категориясен онытмасак иде. Бездә барысы да бар: «Апуш» та, балалар бакчасы да, мәктәп тә. Әмма минем әлегә боларга ихтыяҗым юк. Татарча контент мәсьәләсенә тукталсак, миңа аның башка төре кирәк. Минем интернеттан татар телендә табибларның, икътисадчыларның чыгышларын тыңлыйсым килә. Әмма алар юк. Минем ихтыяҗым канәгатьләндерелми дигән сүз. Ә бит мин – булачак ана. Татар теле кызыклы булсын өчен, аның кәттәлеген расларга кирәк. Моңа мисаллар күп. Әйтик, шуның берсе: татар телен белсәң, инглиз телен бик тиз өйрәнәчәксең. «О, круто!» диярлек факт бит бу!

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Масловка» акционер җәмгыяте генераль директоры (Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы) **Андреев** Николай Васильевич, агросәнәгать комплексы ветераны **Камалеев** Харис Бадретдин улы, «Хезмәт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Һадиев** Рәшид Хафиз улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

«Түбән Кама районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Түбән Кама ветеринария участогы мөдире – ветеринария табибы **Вәлиев** Габделхак Бахит улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Колос» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Андрианов** Николай Александровичка, «Кыят» ачык акционер җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Борисов** Николай Евгеньевичка, Фәйзи Галиев исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы тракторчысы (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Галиев** Ирек Илсур улына, «Колос» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Гуслев** Анатолий Александровичка, «Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Мурдускин** Александр Геннадиевичка, «Нур Баян исемендәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Мөфтиев** Айрат Хәниф улына, «Аксу Агро» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Фатыйхов** Ирек Вазыйх улына, «Маркс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Лениногорск районы) **Шириев** Зиннур Миңневәли улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Кумәч-кондитер комбинаты» акционер җәмгыяте генераль директоры **Котдусов** Булат Фатыйх улына, «Буа шикәре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү участогы операторы **Хуҗина** Гөлзидә Касыйм кызына, «РМ АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җитештерү дирекциясенең ит эшкәртү комбинаты өлкән технологы **Мөбарәкшина** Евгения Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе фитосанитария күзәтчелеге һәм бөртекле ашлыкның сыйфатына күзәтчелек һәм орлыкка контроль бүлеге дәүләт инспекторы **Кадыйрова** Миләүшә Малик кызына, «ГИГАНТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте автомобиль йөртүчесе (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Сәлимов** Илгиз Исмәгыйль улына, «ӘНӘК» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең йөк автомобиле йөртүчесе (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Сираев** Мирзанур Мирзашәех улына, «Чистай» холдинг компаниясе акционер җәмгыяте башкарма директоры урынбасары **Ягафаров** Ирек Фидарис улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

16 октябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кайда син?» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16 +
11.30 «Халкым минем…» 12+
12.00 «Тузган туфрактан күчкәндә» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» 0+
16.00 «Халкым минем…» 12+
16.30 «Кайда син?» 16+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Тузган туфрактан күчкәндә» 16+
23.00 «Исчезнувшая» 16+
00.00 «Соотечественники» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.05 «Нәсыйхәт» 16+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12 +
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели».
20.20 «Ты супер! Суперсезон» (6+).
23.15 «Звезды сошлись» 16+
00.50 «Основано на реальных событиях» 16+
03.20 «ОТДЕЛ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 02.20 «Чудеса» 16+
06.40 «БОЛЬШЕ, ЧЕМ ВРАЧ» 16+
10.15 «Уют за 15 минут» 16+
10.30 «8 ЛЕТ В ОЖИДАНИИ ЛЮБВИ» 16+
14.45 «МУЖЧИНА, КОТОРЫЙ НЕ ХОЧЕТ НА МНЕ ЖЕНИТЬСЯ» 16+
19.00 «ЯРКОЕ ПЛАМЯ» 16+
22.40 «Твой Домашний доктор» 16+
22.55 «АКВАМАРИН» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.50 «ФРОНТ БЕЗ ФЛАНГОВ» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.10 «По горячим следам» 16+
13.40 «Специальный репортаж. Что русскому смешно...» 16+
14.10 «ТАНКИСТ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.40 «Легенды советского сыска» 16+
23.20 «Фетисов» 12+
00.05 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
01.55 «ТРЕВОЖНЫЙ МЕСЯЦ ВЕРЕСЕНЬ» 12+
03.30 «Атомная драма Владимира Барковского» 12+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 16 октябрь

6.00-8.00 «Яңа көн»
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 «Безнең заман әдәбияты үрнәкләре»
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 17 октябрь

6.00-8.00 «Новый день»
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Инструменталь музыка концерты

Чәршәмбе, 18 октябрь

6.00-8.00 «Яңа көн»
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Юллар чатында»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Драма артистлары җырлый

Пәнҗешәмбе, 19 октябрь

6.00-8.00 «Новый день»
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар»

Җомга, 20 октябрь

6.00-8.00 «Иртәнге нур»
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.25 Эстрада музыкасы концерты

Шимбә, 21 октябрь

8.10 «Уйнагыз, гармуннар!»
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Табигать дуслары»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм»
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Данил Салихов. «Яшьлек хатам – йөрәк ярам». К. Тинчурин исем. ТДДһКТ спектакле

Якшәмбе, 22 октябрь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом»
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.10 Ринат Мөхәммәдиев. «Әкәр бабай». Хикәя
15.35, 16.10 Данил Салихов. «Яшьлек хатам – йөрәк ярам». К. Тинчурин исем. ТДДһКТ спектакле

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Студенческий билет, выданный Федеральным Государственным бюджетным образовательным учреждением высшего образования «Российская академия народного хозяйства и государственной службы при Президенте Российской Федерации» Казанский филиал РАНХиГС на имя Лукиановой Мадины Абульфатовны, считать недействительным в связи с утерей.

КУЛ ҖИТМӘС ТҮБӘ

Үз куышың булу – зур бәхет. Бу төшенчәнең кадере көннән-көн арта. Соңгы мәгълүматларга караганда, Казанда ипотекага сатып алган торак өчен ай саен түлисе акча аны арендалау бәясенә караганда 2,4 тапкыр күбрәк чыга. Татарстан әлеге күрсәткеч буенча ил күләмендә дә беренче урынга (!) чыккан. Торак базарында бәяләр кайчанга кадәр үсәчәк? Хәзер фатир сатып алу отышлымы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бер елга – бер миллион сум

Зәлия һәм Рамил Миңнуллиннар 6 ай элек Чаллыдан Казанга күченеп килгән.

– Автокалада әти-әни фатирында яшәдек. Казанга күченү күптәнге хыялыбыз иде. Монда эш тәкъдим иткәч, ике атна эчендә җыенып чыгып киттек, – дип сөйли гаилә башлыгы. – Әлегә туганнарның фатирында торабыз. Казанга күченүгә, үзебезгә сатып алырга торак эзли башладык. Баштарак, фатирны иске йортлардан карадык. Эшкә дә, балалар укыган мәктәпкә дә якын булсын, янәсе. Тик без сайланган арада икенчел торак базарында бәяләр кул җитмәс булып кыйммәтләнде. Ахыр чиктә, шәһәрдән читтәрәк, Лаеш районының Усад бистәсендәге торак комплексында ике бүлмәле фатир сатып алдык. Гаилә ипотекасы буенча ай саен 33 мең сум акча түләргә туры киләчәк. Утыз ел буе! Торакны шәһәр эчендә сатып алам дисәң, айлык түләү якынча ике тапкыр кыйммәтрәк. Андый мөмкинлегебез юк.

Торак базары бүген таганда атынучы баланы хәтерләтә: канат куйганнармыни, гел югарыга талпына. Соңгы айларда тармакка бәйле яңалыклар да аз түгел анысы. Россия Үзәк банкы августта төп ставканы 8,5тән – 12 процентка, сентябрьдә исә 13 процентка кадәр күтәрде, ташламалы ипотека буенча беренчел кертемне 15тән 20 процентка кадәр арттырдылар, ә Татарстан Хөкүмәте Казан тирәсендә торак төзелешенә рөхсәт бирүне вакытлыча тыйды. Җитмәсә, сум да очсызлана. Ә таган җил чыккан саен катырак тирбәлә, билгеле.

– Болар барысы да август аенда торак базарының бик нык җанлануына китерде, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Аңлашыла ки, гади халык кесәдәге акчасын югалтмас өчен, аны эшкә җигеп калырга ашыкты. Сорау арткач, торакка бәя дә үсте. Үзегез уйлап карагыз: узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, Казанда яңа йортлардагы фатир бәяләре уртача 1–1,5 миллион сумга артты.

Кешегә бирү отышсыз

Росреестрның Татарстандагы идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, быелның гыйнвар – август айларында республикада 38 меңгә якын торак ипотекасы рәсмиләштерелгән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, «түбә»ле булырга теләүчеләр 35 процентка күбрәк. Бигрәк тә, август шаккатырган. Җәйнең соңгы аенда Татарстанда фатирларга сорау – 51, Казанда исә 70 процентка арткан.

Бездә торак сатып алу илнең башка төбәкләрендә яшәүчеләрне дә кызыксындыра, ди белгечләр. Росреестрның Татарстандагы идарәсе китергән саннардан күренгәнчә, ел башыннан бирле чит төбәкләрдә яшәүчеләрдән республикада хокуклар һәм башка хезмәтләрне теркәүгә бәйле 10 меңнән артык гариза кабул иткәннәр. Фатирларны барыннан да бигрәк Башкортстан, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсендә, шулай ук Идел буе федераль округы төбәкләрендә яшәүчеләр сатып ала, ди.

Татарстанстат хәбәр итүенчә, бу елның икенче чирегендә Татарстанда иске йорттагы фатирның бер квадрат метры 132 мең сумга җиткән. Яңа йортларда исә әлеге күрсәткеч 180 мең сумлык чикне узып киткән инде.

Казан рекорд та куйган. Соңгы мәгълүматларга караганда, Казанда ипотекага сатып алган торак өчен ай саен түлисе акча аны арендалау бәясенә караганда 2,4 тапкыр күбрәк чыга. Халкы бер миллионнан да артып киткән шәһәрләр арасында беренче өчлеккә Мәскәү (2,3 тапкыр) һәм Санкт-Петербург (2,2 тапкыр) та эләккән.

– Бу – хастаханәдәге уртача температура кебек кенә, әлбәттә, – ди риэлтор Наилә Галиева. – Татарстанда гына түгел, ил күләмендә дә яңа торакның 80–90 проценты ташламалы ипотека программалары ярдәмендә сатыла. Шуңа күрә тәкъдимнәр төрле. Бүген милек бәясе кыйммәт, анысы белән килешмичә мөмкин түгел. Тик үз фатирың өчен түләү – киләчәккә инвестиция икәнен дә истән чыгарырга ярамый. Дөрес, бүген торак сатып алып, аны бурычны каплау хисабына кешегә биреп тору отышлы түгел.

«Атна саен үсә»

Бәяләрне без дә белештек. Гадәттә, гаиләдә бала тугач, торакны яхшырту мәсьәләсе көн кадагына килеп баса. Шуңа күрә «Авито» игъланнар сайтында мәйданы якынча 60 квадрат метр тәшкил иткән ике бүлмәле фатир эзләдек. Башта иске йортлардагы фатирларга күз салыйк: Казан читендә урнашкан «Салават Күпере» торак комплексында, мәсәлән, мондый торакны 5,7 миллион сумга тәкъдим итәләр, Авиатөзелеш районында шундый ук фатирны – 9,2, Җиңү проспекты тирәсендә – 11, ә үзәктә 13 миллион сумга табарга мөмкин. Булган булган, яхшысы булсын дидек тә, «Мега» сәүдә үзәге янында төзелүче яңа комплекста урнашкан әзер ике бүлмәле фатирны белешеп шалтыраттык:

– Мәйданы 63 квадрат метр тәшкил иткән ике бүлмәле торакның бәясе 11 миллион 650 мең сум, – диде төзүче оешма вәкиле Илгизәр. – Төрле ипотека программалары гамәлдә. Тик һәркайсын аерым исәпләргә кирәк. 6 процентлы гаилә ипотекасын рәсмиләштерергә теләсәгез, мәсәлән, беренчел кертем ким дигәндә бәянең 20 проценты күләмендә булырга тиеш. Бу очракта ташламалы ипотека буенча күп дигәндә 6 миллион сум акча алырга мөмкин. Димәк, фатир бәясенең калган өлешен түләү өчен дә акча табарга кирәк.

Исәпләп тә карадык: 11 миллион 650 мең сумлык фатирны гаилә ипотекасы программасы ярдәмендә 20 процент күләмендә беренчел кертем (2 миллион 330 мең сум. – **Ред.**) белән егерме елга сатып алсам, ай саен 66 мең 771 сум акча түләргә туры киләчәк. Түләү вакытын утыз елга кадәр сузсаң, айлык түләү – 56 мең сум. Өч дистә елдан соң ике бүлмәле фатир 20 миллион сумга төшәчәк.

– Фатирлы булу хыялын кичектермәскә киңәш итәбез. Бәяләр атна саен арта. Узган атнада гына да бер бүлмәле фатирлар уртача 100 мең сумга кыйммәтләнде, – дип тә өстәп куйды сатучы саубуллашыр алдыннан.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Торак базарындагы вазгыять турында Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис ХӨСӘЕНОВка сорауларыбызны бирдек.

– Милеккә карата кызыксыну нәрсәгә бәйле?

– Моннан өч ел төзелештә өлешләп катнашу (ДДУ) турындагы канунга үзгәрешләр һәм эскроу-счетлар гамәлгә кергәч, милек базарыннан инвесторлар китте. Ягъни моңа кадәр әле салына гына башлаган йортта очсыз бәядән фатир алып, аны, әзер булгач, кыйммәтрәккә сату мөмкинлеге булса, хәзер болай булмый диярлек. Чөнки әле төзелеп бетмәгән йорттагы фатирның бер квадрат метры бәясе иске торакныкына караганда кыйммәтрәк килеп чыга. Шуңа да карамастан, халык ни өчен яңа фатирларга өстенлек бирә соң? Сәбәбе билгеле – ташламалы ипотека. Аның буенча айлык түләү иске йорттагы фатирныкына караганда кимрәк. Үзәк банк төп ставканы күтәргәч, икенчел торак базары да җанланды. Чөнки моңа кадәр милек базарында вазгыять яхшырганны көтүчеләр дә, алга таба ипотека тагын да кыйммәтләнүдән куркып, фатир сатып ала башлады.

– Алга таба нәрсә булачак?

– Милек базарында сату-алулар саны кимеячәк. Чөнки бүгенге шартларда фатир сатып алырга әзер булучылар күп калмады. Өстәвенә Үзәк банк 1 сентябрьдән кредит бирүгә бәйле таләпләрне катгыйландырды. Йорт яки фатир сатып алучыларның, беренчел кертемгә акчасы булмагач, куллану кредиты алганын бик яхшы аңлыйбыз бит. Әйе, бүген без номиналь яктан да, реаль яктан да халыкның керем дәрәҗәсе артуын сизәбез. Тик бу икътисадның барлык өлкәләренә дә кагылмый. Нигездә төзелеш, сәнәгать кебек тармакларда эшләүчеләрнең хезмәт хакы артты. Ә бюджет тармагын алсак, айлык акча артса да, халыкның керем дәрәҗәсе шул ук.

– Фатир сатып алмасаң, акчаны кая салырга?

– Халык, кулындагы акчасын югалтудан куркып, фатир сатып ала. Әлегә кадәр милек базарында сату-алулар саны кимемәүнең сәбәбе дә нәкъ менә шуңа бәйле. Маяны саклауның икенче юлы – акция, облигацияләр. Әмма махсус белем һәм күнекмәләр булмаган килеш, фонд базарында кертем булдырырга киңәш итмибез. Чөнки бирердә акчаны югалту куркынычы бик зур.

Быелның сигез ае нәтиҗәләре буенча Татарстан төзелеш һәм торакны кулланышка тапшыру күрсәткече буенча Идел буе федераль округында беренче урынга чыккан.

Төбәк	Күрсәткечләр
Татарстан	2,87 млн кв. м
Башкортстан	2 млн кв. м
Түбән Новгород өлкәсе	1,4 млн кв. м

«Ачык Татарстан» сайтыннан

Сәрия МИФТАХОВА

ӘТИ СҮЗЕ

Аларга матур сүзләрне күбрәк әйтерләр, бүләкләр бирерләр. Бәлки сирәк җырларны искә төшерүче дә табылыр. Октябрьнең өченче якшәмбесе Әтиләр көне икән бит. Ә башка вакытта әтиләрнең кадере бармы, сүзләре үтәме, үрнәк була беләләрме? Бу сорауны үзләренә бирдек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Назның артыгы юк.

Тәртипле балалар

Биектау районындагы Әлдермеш мәктәбенең технология укытучысы Фәрит Абдуллин – биш бала атасы. Дөрес, балаларның инде күбесе үз тормышларын корган. «Балаларыгыз тәртипле, яхшы укыйлар, ничек шулай тәрбияли алдыгыз?» дигән сорауны бу гаиләгә еш бирәләр.

– Иркәләп түгел, күбрәк хезмәт белән тәрбияләдем. Таләпчәнрәк булганмындыр. Каеш белән уйнамадым, сүз белән аңлата белдем. Гаилә җанлы кеше мин. Һәрберсен кайгыртырга тырыштым, – ди 65 яшьлек Фәрит абый.

Укытучы дип фырт кына йөрмәгән ул. Кырык ел буе җәен комбайнда хезмәт куйган. Улларын да үзе белән басуга йөрткән: алар комбайнчы ярдәмчеләре булып эшләгән. Укытучы буларак хезмәт юлын егетләрне техника йөртергә өйрәтүдән башлый Фәрит абый. Мәктәпкә килүенә дә 40 елдан артык инде. Башта физкультура укыткан, хәзер – хезмәт дәресләре. Көрәш түгәрәге дә алып барган. Үз уллары да, Сабан туйларында бил алышып, батыр калган. Техникага мәхәббәт тә сеңдергән ул аларга.

Кадет сыйныфларын да укытырга туры килгән аңа. Малайларны, илнең патриотлары булыгыз, дип тәрбияләргә тырыша.

– Мәктәпләрдә хәрби әзерлекне бетереп, дөрес эшләмәделәр. Киләсе елдан кире кайтармакчылар. Элек армиягә бармаган егетне егеткә дә санамыйлар иде. Алар белән кызлар да йөрмәде. Шуңа күрә ватанпәрвәрлек хисен мәктәптә үк яхшылап сеңдерергә кирәк, – ди Фәрит абый.

«Әти» дип дәшәләр

Сарман районының Мортышбаш авылында яшәүче Люция һәм Инсаф Сөнгатуллиннар гаиләсендә – 12 бала: 6 кыз, 6 малай. Инсафның беренче хатыныннан – өч, Люциянең беренче иреннән бер баласы бар. Алар үз тормышын корган инде. Шулар янына тагын сигез баланы сыендырган алар. Хәзерге вакытта төпчекләре Кирилләгә – 7 яшь. Бу җәйдә аның 15 яшьлек абыйсын – Артемны да алып кайтканнар. Хәзерге вакытта йортта 6 бала яши. Арада мәктәптә, көллияттә укучылары да бар. Гөлназ Ижауга медицина юнәлеше буенча укырга киткән. Раилләре инде армиягә барып кайткан.

– Барысы да «әти» дип дәшә. Әти сүзеннән чыкмыйбыз. Бер генә әйтә, ике әйтми Инсаф. Алай кырыс түгел үзе. Яхшы кеше булмаса, шулкадәр баланы үзенеке итеп кабул итә алмас иде. Дөрес, балаларның холкы төрле. Тыңлыйлар, Аллага шөкер. Әмма әтиләре булмаса, тыңлату авыр булыр иде. Безнең өйдә төп кагыйдә – «Каршы әйтмәскә!» – ди Люция ханым. – Өйдәге эшләрне бергәләп башкарабыз. Ирем агроном булгач, җәен басудан кайтып керми. Кечкенә тракторыбыз бар. Улларыбызны техника ияләргә дә өйрәтә.

Яхшы әтигә бүләк тә кызганыч түгел. Балалар бәйрәмнәргә бүләкне үзләре ясарга тырыша. Бу юлы да сөендерми калмаслар әле.

Түгәрәк табын

Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов – ике кыз әтисе. Аның әйтүенчә, гаиләдә үзләрен баш итеп куя алган әтиләр бәхетле. Тик моның өчен күп көч кирәк. Аның бурычы – гаиләне куышлы итү, ризык табу, киендерү. Әти булу – зур җаваплылык. Мин – әти, дип, түр башына утырып, өстәл сугып кына булмый. Син үзең үрнәк булырга тиеш. Әтиләрнең дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Алар – бигрәк тә малайлар өчен үрнәк. Диндә дә әти хакы зур. Кызларны кияүгә биргәндә дә, иң элек әтидән рөхсәт сорыйлар.

– Мин Саба районының Олы Шыңар авылында туып-үстем. Кечкенә чакта безнең авылда әтиләр кайтмыйча, табын янына утыру юк иде, – ди Хәлил Шәйхетдинов. – Ашарга пешсә дә, әни: «Әтиегез кайткач, утырырбыз», – дип әйтә. Көтәбез. Әти юынып, өстәл янына утыра, бездән мәктәп хәлләрен сораштыра. Ул кушканны берсүзсез үтибез. Ишек өстендә тал чыбыгы да бар бит әле. Ул вакытта муллык та, байлык та булмады. Әмма булганына шөкер итеп яшәдек. Әти безне нык тоткан.

> Хәзерге балалар әтиләрен эштән каршы алмый, табынга бергә утырмый. Балалар – телефон, компьютерда, әтиләр үз эше белән мәшгуль. Кызганыч, һәрберсенең – үз тормышы. Кызларым белән бергәләп чәй эчәбез, аралашабыз. Алар мине бик ярата, шул ук вакытта куркып та тора. Әти әйткән икән, ул сүз – закон.

Армиясез булмый

Рөстәм Фәрхиев – Сарман районының Әтиләр берлеге рәисе. Хатыны белән өч кыз һәм бер ул тәрбияли. «Солдат итеге кимәгән – ир түгел» дигән фикердә Рөстәм Фәрхиев. 11 яшьлек Саматны кечкенәдән үк, армиягә барырга, Ватанны сакларга кирәк, дип өйрәтә. Үзе «Спецназ»да хезмәт иткән.

– Дөнья – әтиләр кулында. Шуңа күрә бәйрәме дә булырга тиеш. Соңгы вакытта әтиләрнең кадере артуын сизәбез. Бүгенге вазгыятьтә бигрәк тә. Моңа кадәр әтиләрнең күләгәдә калуын армиягә карата мөнәсәбәткә бәйле дип уйлыйм. Бер ел гына хезмәт итү җитми. Армия бетте икән, ил бетте, дигән сүз. Һәр кеше үз иленең патриоты булса гына, ил нык була, – ди ул.

Самат ике көнгә ярты сәгать булса да, спорт белән шөгыльләнә. Иданнән этелә, турникта тартыла һәм башка күнегүләр ясый. Әтисе кул сугышына да өйрәтә. «Без – терлек карап ныгыган буын. Хәзер авылда маллар юк, заманасы башка. Шуңа күрә физик күнегүләрсез булмый», – ди Рөстәм Фәрхиев.

Әтиле ятимлек

Г.Кариев исемендәге яшь тамашачы театры артисты Нуриәхмәт Сафинга гомере буе әтисез яшәргә туры килгән. Әтиле була торып. «Минем метрикада әти юк иде. Комсомол хезмәткәрләренең, үҗәтләнеп, әтине таптыруыннан гарьләнеп елаган идем ул чакта. Әтисез үскәнемне белмәгәнмени алар?» – дип искә ала ул.

Үзе ятим үскәнгәме, балаларына ата назын бирергә, яхшы әти булырга тырышкан ул. Бер кыз һәм ул тәрбияләгән. Аларга беркайчан да каты бәрелмәгән, тавыш күтәрмәгән. Тормышлары җиңелрәк булсын дип тырышкан. Нуриәхмәт ага әйтүенчә, әтинең сүзе өстен булырга тиеш. Әмма бүген әти-әниләр иртәдән кичкә кадәр эшләгәндә, тәрбиягә вакыт күп калмый. Әти-әни тәрбиясе җитсә, балалар үз-үзләренә кул салмас, биек биналардан сикермәс, бер-берсен җәберләмәс иде. Менә шул хакта да уйлана Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты.

– Әтиләр гаиләдә өстенрәк булырга, балалар бераз шүрләбрәк торырга тиеш дип уйлыйм. Ниндидер начар гамәл кылган икән, үгет-нәсыйхәт белән хатасын аңлату әтидән тора. Каеш белән баланы җиңеп булмый. Сүз, фикер, ышандыру… Шушы әйберләр кирәк, – ди ул.

Бүләк

Казандагы «Өмет» мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт Бикбаев хатыны Энҗе белән дүрт ул тәрбияли. Үзен гаиләсе, балалары өчен хөрмәтле әти дип саный хәзрәт. Аның фикеренчә, әти-әни баласын ялкау итеп үстермәскә тиеш. Ул вакытта балалар чүкечен дә, башка эш коралын да тотачак.

– Аллаһы Тәгалә безгә балаларны бүләк итеп бирә. Әти булу ул – балалар алдында зур җаваплылык. Тәрбияләгәндә, син үз мәнфәгатеңне түгел, ул-кызларыңны кайгыртырга тиеш. Әйтик, кирәкле һөнәрләрне, белемнәрне өйрәтергә, җәмгыятькә файдалы итеп үстерергә. Раббысына итагать итүче булсын өчен, иманны өйрәтү аның беренче бурычы булып тора. Мөхәммәд пәйгамбәребезнең шундый сүзе бар. Әти-әни тарафыннан бирелгән иң зур бүләк ул – күркәм тәрбия, – ди Равил Бикбаев.

Хәзрәт фикеренчә, дингә урын булган җәмгыятьтә әти хакы күбрәк. Әгәр гаиләдә ир – ир урынында, хатын үз урынында булса, бу гаилә тотрыклы булачак.

– Бәйрәмнәргә әллә ни исем китми. Алар календарьда бик күп бит. Әгәр дә ул хөкүмәт тарафыннан кертелгән һәм аның кемнедер искә төшерүдә, хөрмәтләүдә файдасы бар икән, зыяны юк. Әтине хөрмәт итү ул бер көнлек түгел, ә кешенең көндәлек бурычы булырга тиеш, – ди Равил Бикбаев.

ТҮЛӘ ДӘ АЛ

Халыкка салым хатлары килә башлады. Билгеле булганча, физик затларның керемена салымны 1 декабрьгә кадәр түләп бетерергә кирәк. Югыйсә пеня исәпләячәкләр. Шунысын да искәртик: сукыр 1 тиен дә бурыч булып санала.

Салым түләүгә бәйле сорауларны Татарстан буенча 6 нчы номерлы районара салым инспекциясенең баш дәүләт салым инспекторы Рәмзия МӨХЕТДИНОВАга бирдек.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Кемнәр түли?

Физик затларның керемена салымны милекчеләр түли. Торак йорт, фатир, бүлмә, гараж, машина кую урыны, тәмамланмаган төзелеш объекты кебек күчемсез милеккә салым салына. Агымдагы елның 1 декабренә кадәр узган ел өчен хисап тотарга туры киләчәк. Салым күчемсез милекнең кадастр бәясенә бәйле. Тәгаен әйтсәк, ул кадастр бәясенең 0,1 процентын тәшкил итә. Балалар салым түләүдән азат ителми. Яңа туган сабыйга фатирдан өлеш бүлеп биргәнсез икән, димәк, милек рәсмиләштерүнең икенче елында аңа да салым органыннан «сәлам хаты» киләчәк. Балигъ булмаган балалар өчен исәп-хисапны әти-әниләр ясый.

Салымны вакытында түләмәсәң, әҗәтнең – 20, ә моны белә торып та эшләмәү расланган очракта 40 проценты күләмендә штраф салырга мөмкиннәр. Моннан тыш, салым түләргә соңга калган һәр көн өчен Үзәк банкның рефинанслау ставкасының 1/300 өлеше күләмендә пеня исәпләнәчәк. Ул, бурычны каплаганчы, көн саен «тамып» торачак.

Кемнәр азат ителә?

Иң беренче чиратта – пенсионерлар. Шулай ук, әлеге категориягә Советлар Союзы һәм Россия Геройлары, өч дәрәҗәдәге Дан ордены белән бүләкләнүчеләр, I һәм II төркем инвалидлар, тумыштан инвалидлар, инвалид балалар, Бөек Ватан сугышында һәм бүтән хәрби операцияләрдә катнашучылар һәм башкалар керә. Моның өчен кайбер шартлар үтәлергә тиеш. Мәсәлән, милек эшкуарлык өчен файдаланылмаска, аның кадастр бәясе 300 миллион сумнан артмаска тиеш. Ташлама милекнең һәр төре буенча салым түләүче үзе сайлап алган бер объектка карата гына кулланыла. Мәсәлән, пенсионерның ике фатиры, машинасы һәм гаражы бар икән, фатирларның берсе өчен салым түләргә туры киләчәк. Күпбалалы гаиләләр дә милеккә салым түләүдә ташламага ия. Алар һәр бала өчен йортның – 7, фатирның 5 квадрат метр мәйданы өчен генә түли.

Ташламадан файдалану өчен, салым органына мөрәҗәгать итәргә кирәкми. Белгечләр, салым исәпләгәнче үк, кирәкле мәгълүматны үз чыганакларыннан белешәчәк.

Хат килмәсә, нишләргә?

«Салым түләүченең шәхси кабинеты» булганнарга салым хәбәре электрон рәвештә җибәрелә. Шуңа күрә әлеге төр хезмәттән файдаланучыларга шәхси кабинетны тикшереп торырга кирәк. Бу елның 1 июленнән илдә яшәүчеләр электрон салым хәбәрен Дәүләт хезмәтләре порталы аша да алырга мөмкин. Шунысын да искәртик: салым хатын Дәүләт хезмәтләре порталына җибәрергә рөхсәт бирәсез икән, кәгазьдәгесе килүдән туктаячак.

Әгәр дә электрон хезмәтләрдән файдаланмыйсыз икән, салым хаты почта аша киләчәк. Әлеге хатларны милек хуҗаларына, түләү вакыты тәмамланганчы, бер ай алдан таратып бетерәчәкләр. Шуңа күрә һәркемнең салымнар белән танышу һәм исәп-хисап ясау өчен җитәрлек вакыты булачак. Салым күләме ташламалар һәм чигерүләрдән азрак яки 100 сумнан да кимрәк булса, кәгазь хат килми. Кәгазь хат килергә тиеш булып та, ул 1 ноябрьгә кадәр юк икән, салым инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Мондый уңайсызлыклар килеп чыкмасын, дисәгез, салым органнары электрон хезмәтләргә күчәргә киңәш итә. Салымнарны мобиль кушымта яки шәхси кабинет аша өйдән чыкмыйча да түләп була. Биредә үк теркәлгән күчемсез милек объектлары, транспорт чаралары турында мәгълүмат алырга, 3-НДФЛ формасы буенча декларация тутырырга да мөмкин.

Быел нинди яңалыклар бар?

Сизгәнсездер, быел шәхси кабинетта түләнергә тиешле салым күләме фатир, машина өчен аерым-аерым түгел, ә бер сумма булып килде. Эш шунда ки, 2023 елның 1 гыйнварыннан Бердәм салым счеты гамәлгә керде. Ул физик затларга салым түләүләре турында хәбәр җиткерүнең дә яңа формасын күздә тота. Хәзер барлык төр түләүләр берләштерелде. Тиешле акчаны бер тапкыр түлисең дә бетте-китте.

Былтыр ил күләмендә җир кишәрлекләренең кадастр бәясен яңадан исәпләделәр. Алга таба бу җир салымы күләменә тәэсир итәргә мөмкин. Әмма әлеге төр түләү быел ук артып киләчәк дип куркасы юк. Җир салымы өчен бу елга «күчеш чоры» гамәлдә. Ягъни әгәр яңа кадастр бәясе буенча җир салымы күбрәк чыга икән, аны 2022 елгы күрсәткечләр буенча санаячаклар. Ә менә кимрәк чыкса, җир салымын азрак җибәрәчәкләр.

Ике ел элек илдә яңа салым да барлыкка килде. Ул – банк кертемнәре һәм счетлардан алган керемгә салым. Әмма дәүләт гражданнарны 2021 һәм 2022 елларда алган керемнәргә салымнан азат итү турында карар кабул итте. Димәк, агымдагы ел нәтиҗәләре буенча киләсе елда хисап тотарга туры киләчәк.

Милеккә салым чигерүен ничек кайтарырга?

Хезмәт хакыннан, керемнәрдән тотылып калган акчаның бер өлешен салым чигерүе буларак кире кайтарырга мөмкин. «Вычет» берничә төргә бүленә. Арада иң еш кулланыла торганы милеккә салым чигерүедер, мөгаен. Милек бәясенең ике миллион сумыннан «вычет» кайтарып була. Ягъни кеше милек өчен түләгән акчаның 260 мең сумын кире кайтара ала. Салым чигерүе еллык хезмәт хакыннан тотып калынган салым күләмендә түләнә. Калган сумма да янмый, ул киләсе елларга чигерелә. Милек «вычет»ына тиешле сумманы бер объекттан кайтарып бетермәсәң, аны икенчесеннән алырга да мөмкин. Әмма бу 2014 елның 1 гыйнварыннан соң торакны булучыларга гына кагыла. Милекне моңа кадәр үк сатып алгансыз икән, сез салым чигерүенә гомер эчендә бер мәртәбә генә дәгъва кыла аласыз.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Кисәтү хәерлерәк

Барлыгы 15 мең йөрәк авыруы, 2 меңләп яман шеш очрагы. Быелгы диспансеризация барышында республика халкында әнә шулкадәр авыру тапканнар. Һәр ун кешенең берсендә исә теге яки бу чир килеп чыгу куркынычы барлыгын ачыклаганнар. Елның-елында телдән төшмәгән диспансеризациянең ни дәрәҗәдә мөһим тикшерену икәнен аңлау өчен, шушы саннарга күз салу да җитә, ди белгечләр.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының профилактик ярдәм һәм сәламәтлек саклау бүлеге башлыгы Елена Хафизова сүзләренә караганда, 18–39 яшь аралыгындагы кешеләр – өч елга бер, ә 40 яшьтән узганнар һәр ел саен диспансеризация тикшеренүе узарга тиеш. Быел республикада 800 мең кеше табибка күренгән. Ел ахырында бу сан 2,3 миллионга җитәргә тиеш.

– Диспансеризация барышында йөрәк, кан тамыры авыруларының күбесенең кан басымы югары булу аркасында килеп чыкканы ачыкланды. Яман шеш очракларының күбесе башлангыч стадиядә табылды, – дип ачыклык кертте Елена Хафизова.

Яман шешнең барлык төрләре арасында тире, эчәклек, сөт бизләренә бәйле булганнары ешрак очрый. Шуларның яртысы диспансеризация вакытында ачыклана. Аерым алганда, диспансеризация программасы кысасында каралган скрининг технологияләре ярдәмендә сөт бизләре, аналык муентыгы, мәни бизе, эчәклек яман шешен 1–2 стадиядә чакта ук ачыкларга мөмкин.

– Яман чир вакытында сызлау, авырту кебек билгеләр чир инде яхшы ук азганда гына сизелә башлый. Диспансеризация эшне шуңа җиткермәс өчен кирәк тә инде. Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе – тикшеренүне кирәксенмәгән, авыруны азындырганчы йөргән кешеләр, – ди Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш онкологы Эдуард Нагуманов.

Яшерен-батырын түгел, диспансеризация уза алмавын күпләр вакыт җитмәү, эштән китә алмауга сылтый. Закон нигезендә исә эш бирүче диспансеризация узар өчен түләнә торган ял көне бирергә тиеш. 40 яшьтән өлкәнрәк хезмәткәрләргә ул – елга бер, пенсия һәм пенсия яшенә җитеп килүче хезмәткәрләргә ике мәртәбә бирелә. Калганнар аны өч елга бер мәртәбә ала. Диспансеризацияне кичке якта яки шимбә көнне дә узып була.

Диспансеризация вакыты җитмәгән кешеләр исә профилактик тикшеренү дә уза ала. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, узган ел мондый мөмкинлектән республикада яшәүче халыкның яртысыннан артыгы (55,4 процент) файдаланган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ҖЫРЛА, НАЛАСА!

Бу авылны белмәгән татар юктыр. Данлыклы «Наласа авылы көе» аша даны еракларга таралган Арча районының Наласа авылы турында сүзебез. Шул җырны көйләп йөрдек-йөрдек тә без Наласага кузгалдык. Авыл халкы нишләп ята? Наласа нигә картаймый? Авылда гармун моңы ишетеләме? Бер кат Наласа урамнарын әйләнеп, шул сорауларга җавап эзләдек.

Наласаны... йорт баса

«Сезнең авылга килгәнем юк иде әле», – диюем булды, авыл җирлеге башлыгы Илфира Рамазановна, биек «Нива»сына утыртып, Наласа буйлап «сәфәр»гә алып чыгып китте. Авыл зур булганга «сәфәр» дим: бер башыннан икенче башына кадәр йөреп чыкканчы, шактый вакыт узды. Наласа – зурлыгы буенча Арча районында өченче урында.

– Документ буенча, Наласада 230дан артык хуҗалыкта 737 кеше яши. Теркәлмичә яшәүчеләр дә хәйран, – дип сүзен башлады Илфира ханым. – Җирлек башлыгы булып 2012 елдан бирле эшлим. Мин килгәндә, яшьләрнең ыргылып шәһәргә агылган чагы иде. Нытыктып ябыштык без аларга. Авылга федераль, республика программаларын кертә башладык. Һәр елны, ким дигәндә, ике программадан файдаландык. Шулай итеп, бер-бер артлы яңа йортлар калкып чыга башлады, искеләре төзекләндерелде. Ике катлы йортларның барысы диярлек субсидия акчасына салынды. Берсенең дә мәйданы 180 кв. метрдан ким түгел. Шәһәрнең кысан фатиры белән чагыштырырлыкмы, йә?!

Бер мизгелгә Наласада ике катлы йортлар бер катлыларына караганда күбрәк булып тоелды. Санамаганмын гына. Аларның барысында да яшьләр яши, ди. «Менә бу өйне бер яшь гаилә алды. Монысын да, әнә тегесен дә алачаклар», – дип тезеп китте Илфира Рамазановна. Авылда кеше яшәми торган өч йорт калган, алары да сатуга куелган инде.

Яшьләрнең шәһәрне түгел, авылны сайлаулары күпләр өчен гаҗәп, хәтта сәер тоеладыр хәзер. Арагызда ышанмаучылар да бардыр әле. Мәктәбендә 80гә якын укучысы, балалар бакчасында 50ләп баласы булган авыл карт була алмый инде. Әле бу чик түгелдер кебек: юлыбызда бала арбасы тартып йөрүче берничә яшь ханым очрады.

Эшләгән кешегә...

Арчадан 10 чакрым ераклыкта гына урнашкач, Наласадан район үзәгенә барып эшләүчеләр дә бар. Үз эшен булдырган яшьләр, күпләп эре терлек асраучылар да җитәрлек. «Игенче» агрофирмасы булу белән дә бәхетле наласалылар. Даниял абый Нигъмәтҗанов хезмәт юлын моннан 40 ел элек миллионер «Октябрь» колхозында башлый.

– Шушында туып-үстем, 1983 елның язында армия сафларыннан кайттым да башка беркая да китмәдем. Китеп, кая барасың?.. Гаиләдә бердәнбер ир бала, әнине дә калдырасы килмәде. Җитмәсә, ул чакта безнең колхоз бик данлыклы иде, – дип искә ала ул.

Аның сүзенә Марат абый Шаһисламов та кушыла:

– Шофер булып эшләвемә 33 елдан артты, армиядән кайтканнан бирле авылда. Әле күптән түгел улым да хезмәт итеп кайтты. Ул да, авылда калам, дигән була инде. Киленебез нинди туры килер дә, нәрсә эшләп бетәрләр *(көлә)*. Ир – баш, хатын – муен, дигән кебек, киленнәр хәзер ирләрен шәһәргә алып китү яклы бит.

Янібызда торган Илфира ханым да килеште бу сүзләр белән. Яшь ир-егетләрне авылда калдырырга үгетләгәндә, хатыннары сүзеннән чыгару авыр, ди ул: «Ирләр каты торырга тиеш тә бит, юк шул, кайберсен өйрәтергә туры килә».

Читкә киттек. Эш турында бит сүзебез. Нәфесле халык яши монда. Яхшы мәгънәдә, билгеле. Җирлек башлыгы да шулай ди.

– Безгә һаман яхшы кирәк бит, заманча шартларда яшисе килә. Эшләгәне җитмәгән кеше мал-туарын асрый. 10 хуҗалыкка мини-ферма программасы буенча акча юнәттек. Гомумән, авылда узган ел 457 баш эре терлек бар иде, шуның якынча 200 башы – савым сыерлары.

– Хәзер яшәү дә, эшләү дә рәхәт, – дип сүзгә кушыла Даниял абый. – Юк әйберне бар итеп яшәгән чаклар да булды әле...

Шөкер итеп яшәсәләр дә, борчыган проблемаларын да телгә алды алар. Бар җирдәгечә инде: авыл хуҗалыгы продукциясенә бәянең түбән булуы борчый үзләрен. «Дүрттән торып чаба башлыйсың, тырышасың, ә нәтиҗәдә... Хәзер кибеттәге су бәясе дә 25–30 сумнан ким түгел. Без сөтне 21 сумнан тапшырабыз», – ди Марат Шаһисламов.

Яшь йөрәкләр

Без сокланып йөргән дәү йортларның берсендә яшәүче Ләйсән һәм Рөстәм Төхбәтуллиннар аңа карап кына малларын бетерергә җыенмый. Киресенчә, ният-планнары зурдан. Ир бала алып кайтабыз, дия-дия, биш кызлы булган бу гаиләнең мул тормышы – фәкать тырышлык күрсәтү әҗере.

– Хатыным – күрше авыл кызы, ә мин – бөтенләй Яшел Үзән районыннан. Балаларга йөрергә өр-яңа балалар бакчасы, укырга якты мәктәбе бар, яшьләр күп. Наласа шуңа да якын. 9 баш мал асрыйбыз, йорт-җиребезне җиткезеп бетерәсе бар. Ходай саулыктан гына аермасын, – ди гаилә башлыгы.

Наласа киленнәрен бер телгә алган идек бит әле. Тик безгә ирләрен читкә «каеручылар» түгел, авыл өчен җаннарын бирергә әзерләре очрады. Авыл мәдәният йорты мөдире Чулпан Сабирова Наласада 2010 елдан бирле эшли.

– Бүген Наласаны яшьләр яшәтә. 50 яшькә кадәр булганнарны кертмәм мин яшьләргә. Чөнки алар авыл өчен янып-көеп яши, өмә булсынмы, башка чарамы – тиз арада җыелалар, җир җимертеп эшлиләр. Лимонад цехына кадәр бар бит монда...

Аның бу фикерен авылда китапханәче булып эшләүче Гөлчәчәк Сабирҗанова да кабатлады. Дәрвишләр бистәсендә туып-үсеп, Наласа егетенә кияүгә чыккан Гөлчәчәкнең гомерлек хыялы чынга ашкан монда.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Мин кечкенәдән авылда яшәргә хыялландым. Әнием – Әгерҗенең Чишмә авылыннан. Анда яшәүче әби белән бабама сокланып үстем. Ирем бабам кебек булса ярар иде, дип хыяллана идем. Фәрештәнең «амин» дигән сәгатенә туры килде: тавышларына кадәр охшаган аларның, – дип сөйләде ул.

И. Әүхәдиев исемендәге музыка училищесында Винера Ганиеваны укыткан Клавдия Захаровна Щербинина классында, аннан соң педагогика университетында Айдар Фәйзрахманов классында укыган Гөлчәчәк, умартачы егеткә гашыйк булып, Наласа авылына кайта да җыр-моңнарын авылдашларына һәм... китапларга гына бүләк итә. Их, сез аның җырлаганын ишетсәгез иде!

«Наласа авылы көе» җырын сугыш алды елларында авылдан Донбасс шахталарына китеп эшләгән егетләр туган җирләрен сагынудан чыгарган. Гадәттә, алар авылга баеп кайта торган булганнар. Тик барысына да туган якларга кире әйләнеп кайту насыйп булмаган – кайсы шунда тормыш корып калган, кайсын таш баскан... Менә шулар чыгарган да инде халкыбызның «Наласа авылы көе», «Шахта» кебек мәңге үлмәс җырларын.

«Гасырларны кичкән Наласа» китабыннан

«Өздереп гармун уйныйлар...»

Данлыклы җырда җырлана торган бу авылда бүген дә гармун тавышы ишетеләме? Бу сорауны мин юлыбызда очраган һәр кешегә бирдем. «Безнең ярты авыл – көрәшчеләр, калганы – гармунчылар», – дип җавап бирде алар, уенын-чынын бергә кушып. Авылның «Мирас» ансамбленә йөрүче иң өлкән гармунчы Камил Габдрахманов белән дә шул турыда сөйләштек.

– Бездә элек-электән музыкага гашыйк кешеләр бик күп. Минем әти дә пианинода, скрипкада, курайда, тальянда, хромкада, баянда уйный белә иде. Яздырып алган көйләрен әле дә тыңлап шаккатам мин. Бу традицияләр бүген дә саклана. Гомумән, җыр, моң – татарның канына сеңгән төшенчәләр. Безнең халык җырны аңлап башкара. Шуның белән яши, куанганда да, кайгырганда да җырга мөрәҗәгать итә. Мәктәптә район сәнгать мәктәбенең филиалы эшли. Егет-кызлар шактый йөри. Ансамблебез дә бар. Яшерен-батырын түгел, без капиталистик илдә яшибез. Халык та «частник»ка әйләнеп бара. Кеше белән эшләү авыррак хәзер. Әмма, көн саен ук булмаса да, җыелабыз, – дип сөйләде ул.

***

Наласага сәфәребез авыл мәдәният йортында кич утыру белән төгәлләнде. Авылның «Мирас» ансамбле, район мәдәният йортының «Хәзинә» ансамбле һәм авыл халкы белән уйнадык, җырлаштык, серләштек, көлештек тә, «Наласа көе»н көйли-көйли, «Җырлап яшә, Наласа!» – дип, Казаныбызга кайтып киттек.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ГАЛИЯ ТЯМАЕВА: «НИЧЕК ОЯЛМЫЙЧА ӘШСЕЗ ЯТЫЙК?»



Галия Тямаеваның шәхси архивыннан

Галия апа балалары белән бик горурлана. Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаевны, батыр йөрәкле Фирзәр, кешелекле, ярдәмчел Лилияне үстергән әни нинди ул? Аның белән авырлыктан соң килгән җиңеллек, сабырлыкның әҗере, бала һәм әни кадере турында сөйләштек.

– Без 11 балалы гаиләдә үстек. Әниебезнең гомере кыска булды. 52 яшендә китеп барды. Ул вакытта кечкенә сеңлебезгә нибары 4 яшь, ә мин 10 нчы сыйныфта укый идем. Шуннан соң эти бернечә тапкыр өйләнде. Туганнарыма үги әни белән яшәүнең ни икәнен татырга туры килде, – дип искә ала ул. – Бик авыр булса да, кеше булдык, барыбыз да аякка бастык. Кызганыч, бер абыем белән энем исән түгел инде.

Галия апага югалту ачысын күп мәртәбәләр татырга туры килә әле. 42 яшендә өч баласын калдырып, ире Фәрит вафат була.

– Көн-төн эштә булдык. Ирем энергетик иде. Мин төрле эшләрдә эшләдем. Фермада да, ашханәдә дә хезмәт куярга туры килде. Балаларны көнозын күрми идек. Шөкер, яхшы кеше, тормышны яраткан кеше булып үстеләр. Фирдүс кечкенәдән музыкага тартылды, Фирзәр, авылны яратам, монда калам, диде. Лилия дә бик уңган-булган, – дип сөйли Галия апа.

Тол калганнан соң Галия апа яңадан тормыш кора. Иптәшенең дә балалары бар. Аралашып яшиләр икән.

– Ялгыз тормыш итүләре бик кыен булды. Ялгызлыгын да күтәрерсең, әмма кеше янында сыңар канат булмыйм, дидем. Иптәшем белән 16 ел бергә яшибез инде. Бик тыныч, акыллы кеше. Балаларның һәркайсының үз гаиләсе, үз тормышы бит. Олыгайган көндә терәк кирәк, – ди ул.

Балалары гына түгел, кияү-киленнәре турында да бик яратып сөйли Галия апа. Төп йортта улы Фирзәр, киленe Румия белән яшиләр икән. Шактый сөйләшсәк тә, Галия апа Румияне бер дә «киленем» димәде. «Кызым» дип кенә тора. Бәхетемә безнең йортка килгән бала, ди ул аны. Галия апа операция ясаткан, төп эш Румия җилкәсендә. Әниләренә авыр эш эшләтмәскә тырышалар.

– Күршедә генә яшәгән Румия 19 яшендә миңа килен булып килде. Үз йортындагы тәртип анда кала, монда минемчә була инде, дидем. Шөкер, бик җайлы яшәп киттек. Беренче көннән үк яраттым үзен. Үз балам кебек Румиям. Без аның белән ярты сүздән аңлашабыз, – ди Галия апа. – Фирзәр улым белән Румия ике бала үстерәләр. Кызыбызга әниемнең исемен куйдырдык.

Кызы – Лилиясенең тормышына да шөкер итә ул. Киявем белән ике бала үстерәләр, алар өчен күңелем тыныч, ди. Һәр баласыннан игелек күрүенә сөенә.

> Фирдүсем уңәтлеге белән күтәрелде. Баламның тамашачысына ихлас күңелдән рәхмәтемне җиткерәм. Яратуыгыз өчен рәхмәт.

– Балаларым олы йөрәкле. Аларга кеше кайгысы чит түгел. Фирдүсем дә, Фирзәрем дә махсус хәрби операциядәге егетләргә ярдәм итә. Киявем дә алар белән. Үзем дә булдыра алганча өлеш кертәм. Каз мае әзерләп бирәм, бал, сарымсак җибәрәм. Кемнәрнеңдер бәгырькәйләре бит алар да, – ди ул.

Фирзәр дә, Фирдүс тә башта егетләр янына баруларын әниләренә әйтеп тормаган. Фирзәре 12 тапкыр барып кайткан инде. Бервакыт Галия апа Фирдүстән: «Фирзәр кайда?» – дип сорагач, «Мәскәүдә ул, эшләр буенча йөри», – диган. Эче пошкан Галия апа Резедага да шалтыраткан. Анысы да: «Әни, сиңа дип, Түбән Новгородта сырлар карап йөри», – ди икән. Фирдүс кайтып, әнисенә энесе җибәргән рәсемнәрне күрсәткәч кенә сер ачыла.

– Ана йөрәген алдап буламы соң? Сизендем бит мин аны. Шушы очрактан соң улларымны яныма утырттым да, башка миңа әйтми китмәгез, дидем. Алар кайтып җиткәнче догада булам, – ди ул.

65 яшьлек Галия апаның маллар тотуын күбебез белә. Авылда терлек асрамау – оят, ди ул. 5 танасы бозаулаган инде, тагын икесе тиздән сөенделәчәк. Үгезләре дә күп. Аларның санын әйтмәде. Ә менә 100 каз үстергәнен яшермәде. Әле аның янына күп итеп тавыклар да алган. Ялгыз яшәсә дә, кодагые – Румиянең әнисе дә күп итеп маллар тота икән.

– Печәнен дә, фуражын да ала. Малын бетерми. Кодагый берүзе эшләп ятканда, без ничек оялмыйча әшсез ятыйк? Операциядән соң саклан, дисәләр дә, маллар янына чыккалыйм инде. Йөрәгемә сеңгән эш бит. Абзарга чыгып эшләп керү рәхәт миңа. Эшли алу – үзе бәхет, – ди Галия апа. – Саулык кирәк. Ул булса, бар да була. Сәламәт кеше акчасын да таба. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләдән сәламәтлек сорагыз. Иң зур бәхет менә шул дөньяда. Җир йөзенә бер генә киләбез, матур итеп яшик!

ЯШӘҮ ЯМЕМ – ХАТЫНЫМ

Салиховларның шәхси архивыннан

Айрат Салихов инде 29 ел аягына баса алмый. Әмма җир җимертеп дөнья көтәргә тырыша. Актаныш районының Киров авылында хатыны Ләйлә белән сөт җыялар.

Айрат 29 яшендә авариягә очрый. 1994 елның 11 октябрендә була бу хәл.

– Энем белән күрше авылга бара идек. Башта рульдә мин бардым, аннары ул утырды. Тизрәк барып җитәсе килгән иде, – дип искә ала Айрат. – Уянып киткәндә мин инде Актаныш хастаханәсендә идем.

Хатыны Ләйлә ул чакта район хастаханәсенең балалар бүлегендә шәфкать туташы булып эшли.

– Табиблар кисәтеп куйды: Айратның 7 сәгать гомере калган. Мин ышанмадым. Ничек инде, яши ул, безнең әле оныклар сеясе бар, дим. Аннары, 14 көннән үлә, диделәр. Тагын ышанмадым. Айратымның яшисен сизендем. Бер Аллаһы Тәгаләгә ышандым һәм аннан иремә гомер сорадым. Авырга узган идем. Туачак сабыем, өйдәге кызымны әтисез итмә, Раббым, дидем, – ди ул. – Шөкер, ирем 58 яшен тутырды инде. Күпләр, икенче бәбиеңне алып кайтма, дигәндә дә, баламны алдыру иремне ташлауга тиң булыр иде, дидем. Иремнең йөри алмавын язмыш сынавы дип кабул иттем.

Йөри алмаячагын ишетү Айратка бик авыр була. Әмма язмыштан узмыш юк. Иясләшергә, яңача тормыш итәргә өйрәнергә туры килә. Ә Ләйлә олы кызын әти-әнисендә калдырып, ире белән хастаханәдә яши башлый.

– Нәрсә дип әйтергә дә белмим, 1994 елда безнең авылда 4 кеше аяксыз калдык. Хәсрәткә чумып, шуннан чыга алмаучылар да була бит. Янымда Ләйләм булмаса, белмим, нишләп бетәр идем икән. Минем дә ялгышкан вакытларым булды. Шуңа күрә бүгенге тормышым өчен Ләйләгә рәхмәт, – дип сөйли Айрат күз яшьләрен тыя алмыйча. – Көчле рухлы булды. Сынарга ирек бирмәде. Барыбызга да бик авыр булды. Энем бу авариядә үзен гаепле итеп санады. Шул хәсрәтне күтәрә алмады.

Салиховлар авырлыкларны эш белән җиңәргә тырыша. Моннан 20 еллар элек авылларында сөт җыя башлыйлар. Башта үзләренә трактор алып, анда башка кешене утырталар. Ә аннары Айрат махсус машина алып, рульгә үзе утыра.

Матур гына тормыш иткәндә, алар капкасын тагын борчу җиле шакый. Ашказанын күрсәтергә барган Айратның бөерендә табиблар яман шеш таба. Шөкер, операцияне вакытында ясап өлгерәләр.

– Аллаһы Тәгалә миңа ике тапкыр гомер бирде. Ике як туганнарым, балаларым терәк булды. Ике кызым, ике киявем, 5 онытыбыз бар. Кызлардан күргән хөрмәтне белсәгез иде! Ул кияүләрем күтәреп кенә йөртми инде. Шулкадәр яраталар. Минем шикелле бәхетле кеше юктыр, дим. Бөтен эшне эшлим, ут та кертәм, мал да карыйм, тәзәтәм дә, – ди Айрат. – Иң зур рәхмәтне хатыныма әйтәм. Хатын-кызны яратыгыз. Ул да сезгә ярату белән җавап бирәчәк. Кадерләрлек кешегезне кадерләргә кирәк. Тормышта авырлык тикмәгә бирелми. Борчу-хәсрәт үзе куркып, сездән ерак йөрсен, дисәгез, мин булдырам, мин яшим, диярге кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

2–20 октябрь – ташламалы бәядән язылу көннәре

П2435 (җомга) >> ~~571 сум 98 тиен~~ **497 сум 34 тиен**

П2409 (сиш., чәрш., җомга) >> ~~1255 сум 86 тиен~~ **1086 сум 18 тиен**

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана. 19 октябрьдә – **«Казан сәлам» милли киемнәр брендыннан ШАРФ** уйнатыла

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

Бу атна җиңүчесе – Нурлат шәһәрендә яшәүче Минвәли Гаяз улы Хәснетдинов. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуызны үтенәбез!



Әз-мәз мәзәк

Маникюр, педикюр, макияж, эпиляция... Эх! Балачакта бу әйберләрне бер генә нәрсә алыштыра иде – баш түбәсендәге бантик.

***

Төнлә сөртергә кирәкле крем кайчан көн, кайчан төн икәнен каян белә икән?

***

– Иртәгә тәрәзә пәрдәләренә акча җыешабыз.
– Апа, сез бит репетитор, өйдә генә укытасыз.
– Минем өйдә тәрәзәләр юк дип белдемме әллә?

***

Бу даруның нәтиҗәсе булсын өчен, аны авыруны иярткүгә бер атна кала эчә башларга кирәк.

***

– Илнур, Африкада яшәүче биш хайванны ата.
– Өч маймыл һәм ике жираф.

***

Иң рәхәт нәрсә – йоклау һәм ашау. Беренчесе әле бушка да.

Беләсең килсә...

1 «Мерседес» маркаларын халыкта ничек дип йөртәләр? «Мерседес» маркасының CLS модельләрен халыкта ничек дип йөртәләр?
а) таран;
б) кабан;
в) банан.

2 Язучы Рәшит Зәкиев кайсы татар журналын җитәкләде?
а) «Казан утлары»;
б) «Идел»;
в) «Чаян».

3 Төрекләр яратып пешерә торган ясмык ашы ничек дип атала?
а) мәрхәбә;
б) мәрҗимәк;
в) мәслихәт.

4 Карабахны икенче төрле ничек атыйлар?
а) Арцах;
б) Нахичевань;
в) Сюник.

Җаваплар: 1. в); 2. в); 3. б); 4. а).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: сукояр, Арча, Луара, ел, Ландыш, Ту, туу, Ола, инуит, фук, Ан, урама, су, Ралиф, латте, Шамил, он, шалкан, салмак, Ак, бур, Фәрхи, рәт, РАН, куас, Штерә, чибәр, ату, аудару.

Вертикаль: Светофор, фарш, Лулу, ашханә, ата, ки, акула, ренет, Рим, мех, ру, яла, афиша, Иркә, рун, лак, адмирал, ачу, ары, алка, Сид, Раштуа, акбур, ба, Уинстон, әр, армут, уен, арттыру.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 340

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+